536. «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...............................................220
537. «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...............................................222

538. «Татарстан Республикасының Инвестиция советы составына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................................223
539. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........224
540. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........224
541. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........225
542. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........225
543. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........225
544. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........226
545. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........226
546. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........227
547. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........227
548. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........228
549. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........228
550. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........229
551. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........229
552. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........232
553. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........233
554. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........233
555. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........234
556. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........234
557. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........234
558. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........235
559. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........236
560. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........236

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 359. «Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» 2011 елның 10 октябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү нигезләре һәм шартлары**

1. Инвестицияле салым кредиты салым органнарында исәптә торучы һәм Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмага түбәндәге нигезләр буенча бирелергә мөмкин:

1) Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән нигезләрнең берсе булганда;

2) әлеге оешма тарафыннан яңа производство төзү һәм (яисә) гамәлдәге производствоны реконструкцияләү башкарылганда.

2. Инвестицияле салым кредиты алу өчен нигезләр оешма тарафыннан документаль расланган булырга тиеш.

3. Инвестицияле салым кредиты бер елдан алып түбәндәге срокка бирелә:

1) өч елга кадәр, шул елны да кертеп, – Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча аеруча мөһим заказ үтәүче яисә халыкка аеруча мөһим хезмәтләр күрсәтүче йә дәүләт оборона заказын үтәүче оешмалар өчен;

2) дүрт елга кадәр, шул елны да кертеп, – капитал салулар 350 миллион сумнан артык булмаган инвестиция проектлары өчен;

3) биш елга кадәр, шул елны да кертеп, – капитал салулар 350 миллион сумнан артык булган, әмма 800 миллион сумнан артып китмәгән инвестиция проектлары өчен;

4) җиде елга кадәр, шул елны да кертеп, – капитал салулар 800 миллион сумнан артык булган инвестиция проектлары өчен.

4. Инвестицияле салым кредитын һәм исәпләнгән процентларны түләү вакыты инвестицияле салым кредиты бирү срогына керә һәм түбәндәгене тәшкил итә:

1) өч елдан артык түгел – әлеге статьяның 3 өлешендәге 1 – 3 пунктларында күрсәтелгән инвестиция проектлары өчен;

2) алты елдан артык түгел – әлеге статьяның 3 өлешендәге 4 пунктында күрсәтелгән инвестиция проектлары өчен.

5. Инвестицияле салым кредиты түбәндәгечә бирелә:

1) Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктының 1, 5 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча – бу пунктчаларда санап үтелгән максатларда гына файдаланыла торган, оешма тарафыннан сатып алынган җиһаз бәясенең 100 процентын тәшкил итүче кредит суммасына;

2) Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инвестиция эшчәнлеген җайга салу һәм дәүләт ярдәмен күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле органы (алга таба – вәкаләтле орган) һәм оешма арасындагы килешү буенча билгеләнә торган кредит суммасына, әмма инвестиция проекты бәясенең 50 процентыннан артык түгел;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктының 3, 4 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча – вәкаләтле орган һәм оешма арасындагы килешү буенча билгеләнә торган кредит суммасына, әмма дәүләт контракты бәясенең 10 процентыннан артык түгел;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктының 6 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча –

«Россия Федерациясендә территориаль үсеш зоналары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 3 декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвестиция проектларын территориаль үсеш зоналары резидентлары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен каралган һәм файдаланылучы, амортизацияләнә торган мөлкәтне сатып алуга, булдыруга, җиһазлап бетерүгә, реконструкцияләүгә, модернизацияләүгә, техник яктан яңадан коралландыруга капитал салулар чыгымнары суммасының 100 процентыннан артык булмаган кредит суммасына;

5) әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән нигез буенча – вәкаләтле орган һәм оешма арасындагы килешү буенча билгеләнә торган кредит суммасына, әмма инвестиция проекты бәясенең 10 процентыннан артык түгел.

6. Салым чоры дәвамында тупланган кредит суммасы, Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 пунктының 1, 2, 5, 6 пунктчаларында һәм әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча, бизнес-план нигезендә бу салым чорында оешма тарафыннан инвестиция проекты кысаларында түләнергә тиешле салым суммасыннан, шулай ук, бу салым чоры өчен инвестицияле салым кредиты турында шартнамәләрнең булуын исәпкә алмыйча, гомуми кагыйдәләр буенча билгеләнгән тиешле салым түләүләре күләмнәренең 50 процентыннан артып китә алмый.

7. Инвестицияле салым кредитыннан файдаланган өчен процент ставкасы инвестицияле салым кредиты турындагы шартнамә төзелгән вакытка Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге рефинанслау ставкасының икедән бере күләмендә билгеләнә.

8. Инвестицияле салым кредиты бирү турында карар инвестицияле салым кредиты буенча бурычны, шул исәптән инвестицияле салым кредитыннан файдаланган өчен процентларны каплау өчен җитәрлек дәрәҗәдә оешма тарафыннан тәэмин ителү шарты үтәлгәндә кабул ителә.

9. Инвестицияле салым кредитын кире кайтару йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү алымнары мөлкәт залогы йә поручительлек булырга мөмкин.

10. Оешма Россия Федерациясе Салым кодексының 73 статьясында каралган тәртиптә тапшырыла торган залог предметы булып торган мөлкәткә карата мөлкәт иминияте шартнамәсе төзи. Мөлкәт иминияте шартнамәсенең

гамәлдә булу срогы инвестицияле салым кредиты турындагы шартнамәнең гамәлдә булу срогыннан ким була алмый.

11. Инвестицияле салым кредиты түбәндәгеләр булмаганда бирелә:

1) оешманың Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлары;

2) инвестицияле салым кредитын бирү өчен нигез булып торган инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен оешмага бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт ярдәменең башка рәвешләре.

12. Инвестицияле салым кредиты бирүгә юнәлдерелә торган акчалар күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон белән билгеләнә.»;

2) 5 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инвестиция эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен җайга салу һәм бирү өлкәсендә вәкаләтле органы» сүзләрен «вәкаләтле орган» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 марты
№ 16-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 360. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 21 июль, 17 ноябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $15^1$ статьяның 1 өлешендәге 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Муниципаль районның җирле администрациясе муниципаль районның административ үзәге булып торган җирлекнең җирле администрациясе вәкаләтләрен әлеге Законның 21 статьясындагы 4 өлешенең өченче абзацында каралган очракларда муниципаль район бюджетының үз керемнәре һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән гамәлгә ашыра.»;

3) $17^1$ статьяның 1 өлешендәге 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

4) 18 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

«$6^1$) җирлекләрнең, шәһәр округларының коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерүнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан таләпләр билгеләнә торган программаларын эшләү һәм раслау;».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, шушы Законның 1 статьясындагы 4 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 30 декабрендәге 289-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы үз көченә кергән көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 марты
№ 17-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 361. «Татарстан Республикасында суд участокларын төзү һәм җәмәгать судьялары урыннарын булдыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында суд участокларын төзү һәм җәмәгать судьялары урыннарын булдыру турында» 2000 елның 31 маендагы 177 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 6 (5); 2007, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) «Казан шәһәрендә – 56» сүзләрен «Казан шәһәрендә – 60» сүзләренә алмаштырырга;

б) «Чаллы шәһәрендә – 22» сүзләрен «Чаллы шәһәрендә – 24» сүзләренә алмаштырырга;

2) кушымтада:

а) утыз беренче абзацта «22» саныннан соң «, 23, 24» саннарын өстәргә;

б) кырык сигезенче абзацта «7» саныннан соң «, 8» санын өстәргә;

в) илле беренче абзацта «10» саныннан соң «, 11» санын өстәргә;

г) илле икенче абзацта «10» саныннан соң «, 11» санын өстәргә;

д) илле өченче абзацта «11» саныннан соң «, 12» санын өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 марты
№ 18-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 362. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2004, № 3 (I өлеш), № 4 – 5, № 10, № 11; 2005, № 7 – 8, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (II өлеш); 2008, № 5 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2009, № 6, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2 статья. **Салым ставкалары**

1. Салым ставкасы, әлеге статьяның 2 өлешендә башкача каралмаган булса, 2,2 процент күләмендә билгеләнә.

2. Гомуми файдаланудагы тимер юлларга, магистраль торбаүткәргечләргә, электр тапшыруы линияләренә, шулай ук күрсәтелгән объектларның аерылгысыз технологик өлеше булып торган корылмаларга карата салым ставкалары 2013 елда – 0,4 процент, 2014 елда – 0,7 процент, 2015 елда – 1,0 процент, 2016 елда – 1,3 процент, 2017 елда – 1,6 процент, 2018 елда 1,9 процент күләмендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай узгач үз көченә керә һәм 2013 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 марты
№ 19-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 363. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йорт-

ларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), «1 апреленнән» сүзләрен «30 апреленнән» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 марты
№ 20-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 364. «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш), № 12 (VI өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; Ватаным Татарстан, 2012, 21 июль), «2013 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2018 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның гамәлдә булуы 2013 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 марты
№ 21-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 365. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 3; Ватаным Татарстан, 2013, 19 гыйнвар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^1$ һәм $6^2$ пунктчалар өстәргә:

«$6^1$) Татарстан Республикасы тарихы һәм мәдәнияте өчен аерым әһәмияткә ия тарихи җирлекләр (алга таба – төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекләр) исемлеген, төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекне саклау предметын, төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрен раслау;

$6^2$) төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата әзерләнгән генераль планнар проектларын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларын килештерү;»;

2) 30 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Хуҗалык ягыннан үзләштерелергә тиешле территориядә Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәй дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары һәм ачыкланган мәдәни мирас объектлары урнашкан очракта, күрсәтелгән объектлар территориясе чикләрендәге җир кишәрлекләренә турыдан-туры бәйле территорияләрне хуҗалык ягыннан үзләштерү эшләре мондый эшләрне үткәрү проектларында шушы мәдәни мирас объектларының яисә ачыкланган мәдәни мирас объектларының сакланышын тәэмин итү турында һәм проект документациясенә экспертизаның уңай бәяләмәләрен алган бүлекләр булганда гына башкарыла.»;

3) 32 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32 статья. **Тарихи җирлекне саклау предметы**

1. Тарихи җирлекне саклау предметына түбәндәгеләр керә:

1) шәһәр барлыкка китерә торган тарихи яктан кыйммәткә ия объектлар – тарихи корылышны барлыкка китерә торган һәм шул исәптән масштаб, күләм, структура, стиль, конструктив материаллар, төсле бизәлеш һәм декоратив элементлар нигезендә берләштерелгән биналар һәм корылмалар;

2) планировка структурасы, аның элементларын да кертеп;

3) күләм-пространство структурасы;

4) корылманың композициясе һәм силуэты – вертикаль һәм горизонталь доминанталарның һәм акцентларның чагыштырмасы;

5) төрле шәһәр пространстволары арасындагы чагыштырма (буш, төзелеп беткән, яшелләндерелгән);

6) композиция-күренеш бәйләнешләре (панорамалар), табигый һәм кеше барлыкка китергән әйләнә-тирәнең чагыштырмасы.

2. Тарихи җирлекне саклау предметы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан һәр тарихи җирлеккә карата раслана.

3. Төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекләр исемлеге, төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекне саклау предметы Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.»;

4) 33 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33 статья. **Тарихи җирлек территориясе**

1. Тарихи җирлек территориясе тиешле торак пункт чикләрендәге территориядән гыйбарәт. Тарихи җирлек территориясенең чикләре торак пункт чикләре белән туры килмәскә дә мөмкин. Тарихи җирлек территориясенең чикләрен билгеләүгә таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

2. Төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләре, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә вәкаләтле органы белән килештереп, Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланa.

3. Төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясенең әлеге статьяның 2 пунктында билгеләнгән тәртиптә расланган чикләре торак пункт чикләре белән туры килмәскә дә мөмкин.»;

5) 34 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34 статья. **Тарихи җирлектә шәһәр төзелеше, хуҗалык итү эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек**

1. Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәй дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының, тарихи җирлекне саклау предметының сакланышын тәэмин итү максатларында, мондый җирлектә шәһәр төзелеше эшчәнлеге, әлеге Законда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә махсус җайга салынырга тиеш.

2. Тарихи җирлектә шәһәр төзелеше эшчәнлеген махсус җайга салу җирле үзидарә органнары тарафыннан башкарыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәй дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының, тарихи җирлекне саклау предметының сакланышын тәэмин итүне исәпкә алып, тарихи җирлек территориясенең торышын, аны тотрыклы үстерү проблемаларын һәм юнәлешләрен анализлау;

2) тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү чараларының исемлеген билгеләү;

3) тарихи җирлекнең планировка структурасын саклап калуга, биналарның һәм корылмаларның күләмнәренә һәм пропорцияләренә, аерым төзелеш материалларын кулланууга, төсле бизәлешкә карата таләпләрне исәпкә алып, рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләүнең иң чик параметрлары, автомобильләр кую урыннарын, реклама һәм элмә язуларны урнаштыруга тыюлар яки чикләүләр, Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәй дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының, тарихи җирлекне саклау предметының сакланышын тәэмин итү өчен кирәкле башка чикләүләр каралган шәһәр төзелеше регламентларын эшләү;

4) төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата әзерләнгән генераль планнар проектларын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларын әлеге Закон нигезендә килештерүне тәэмин итү.

3. Төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата әзерләнгән генераль планнар проектлары федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә вәкаләтле органы белән килештерелергә тиеш.

4. Җирдән файдалануның һәм төзелеш алып баруның төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата әзерләнгән кагыйдәләре проектлары Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә вәкаләтле органы белән килештерелергә тиеш.

5. Төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата әзерләнгән генераль планнар проектларының, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларының тарихи җирлекнең расланган саклау предметына туры килүе күрсәтелгән проектларның килештерү предметы була.»;

6) 35 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35 статья. **Тарихи җирлекнең тарихи-мәдәни терәк планы**

1. Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәй дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары, тарихи җирлекне саклау предметын тәшкил итә торган сакланып калган һәм юкка чыккан объектлар, мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләре, мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләре, тарихи җирлек территориясе чикләре тарихи җирлекнең тарихи-архитектура, тарихи-шәһәр төзелеше, архив тикшеренүләре һәм археологик тикшеренүләр нигезендә төзелә торган тарихи-мәдәни терәк планында чагылыш таба.

2. Тарихи-мәдәни терәк планы Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәй дәүләт реестры белешмәләре, тарихи-мәдәни тикшеренүләр материаллары, тарихи-архитектура терәк планнары, Татарстан Республикасының тарихи территорияләрен тарихи-мәдәни бәяләү күрсәткечләре һәм мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавының, аларны саклап калуның һәм алардан файдалануның башка белешмәләре нигезендә документлаштырылган һәм автоматлаштырылган рәвештә Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы тарафыннан төзелә һәм алып барыла.

3. Төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекнең тарихи-мәдәни терәк планы турында нигезләмә Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, физик һәм юридик затларның тарихи җирлекнең тарихи-мәдәни терәк планыннан файдалана алуы территориаль планлаштыруның дәүләт федераль мәгълүмат системасы аша тәэмин ителә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 марты
№ 22-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 366. «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстын раслау өлешендә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (I өлеш); 2002, № 12 (II өлеш); 2003, № 8; 2006, № 2 (I өлеш), № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«18 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт гимны – әлеге Законда каралган очракларда башкарыла торган музыкаль-поэтик әсәр.

Татарстан Республикасы Дәүләт гимнының музыкаль редакциясен һәм текстын әлеге Законның 3 нче һәм 4 нче кушымталары нигезендә расларга.»;

2) 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«24 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт гимны оркестр, хор, оркестр-хор йә башка вокаль яисә инструменталь вариантта башкарылырга мөмкин. Бу чакта тавыш язу чаралары кулланылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Дәүләт гимны расланган музыкаль редакциясенә һәм текстына төгәл туры китереп башкарылырга тиеш.»;

3) түбәндәге эчтәлекле 4 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасының
дәүләт символлары турында»
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт гимны
тексты
(Рамазан Байтимеров сүзләре,
рус теленә Филипп Пираев тәрҗемәсе)

Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,
Халкым тели изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.
Күп гасырлар кичкән чал тарихлы
Данлы илем, үзең бер дастан!
Синдә генә безнең язмышыбыз,
Республикам минем, Татарстан!

Цвети, священная земля моя,
Да будет мирным твой небосвод!
Единый дом у нас, одна семья,
Живет в согласии наш народ.
Богатый мудростью седых веков,
Надеждой, верою ты нам стал,
И пусть хранит тебя моя любовь,
Моя Республика, мой Татарстан!».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 18 марты
№ 23-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 367. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 2 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяда:

а) $6^1$ өлештә «иренең яисә хатынының һәм балигъ булмаган балаларының» сүзләрен «үз гаиләсе әгъзаларының» сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 өлештә «Әлеге статьяда» сүзләреннән соң «һәм әлеге Законның $17^1$ статьясында» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $17^1$ статья өстәргә:

«$17^1$ статья. **Чыгымнар турында белешмәләр тапшыру**

1. Дәүләт хезмәтенең Россия Федерациясенең тиешле норматив хокукый акты белән билгеләнгән исемлегенә кертелгән вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәре федераль за-

конда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Президентының алар нигезендә кабул ителгән указында билгеләнгән тәртиптә үз чыгымнары, шулай ук үз гаиләсе әгъзаларының чыгымнары турындагы белешмәләрне яллаучы вәкиленә тапшырырга тиеш.

2. Дәүләт хезмәткәренең һәм аның гаилә әгъзаларының чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның чыгымнарын, шулай ук аларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын тикшереп торуны гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт органы (дәүләт органы бүлекчәсе йә күрсәтелгән органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты) Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.

4. Дәүләт хезмәткәренең үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау яисә тулысынча яки дөрес итеп тапшырмау йә үз гаиләсе әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау яисә тулысынча яки дөрес итеп тапшырмау, әгәр мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булса, дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәтеннән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10[1] статьяда:

а) исемендә «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

б) 1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат ел саен «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр, хисап финанс елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә (алга таба әлеге статьяда – комиссия) тапшырыла.

2. Депутатның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр әлеге Законның 1 – 3 нче кушымталары нигезендәге белешмәләр формалары буенча тапшырыла.»;

в) 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үзенең чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, әгәр алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда төп хезмәт (эш) урыны буенча гомуми кеременнән артса, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.»;

г) 4 пунктта «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

д) 5 пунктта «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;
е) 6 пунктта «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

2) $10^3$ статьяда:
а) исемендә «Керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

б) 1 пунктның 1 пунктчасында «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

в) 2 пунктта «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

г) 6 пунктның 4 пунктчасында «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

д) 7 пунктның 3 пунктчасында «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

е) 18 пунктта «Керемнәр,» сүзеннән соң «чыгымнар,» сүзен өстәргә;

ж) 20 пунктта «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

3) $10^4$ статьяда:
а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$10^4$ статья. **Депутатлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, акчаларны алу чыганаклары хакында тапшырыла торган белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларының соравы буенча аларда бастырып чыгару өчен бирү тәртибе»;**

б) 1 пунктта:
беренче абзацта «һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла» сүзләрен «һәм массакүләм

мәгълүмат чараларының соравы буенча аларда бастырып чыгару өчен тапшырыла» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алу буенча чыгымнар турында, әгәр алыш-биреш суммасы депутатның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда төп хезмәт (эш) урыны буенча гомуми кеременнән артса, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турындагы белешмәләр.»;

в) 2 пунктта:

беренче абзацта «һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла» сүзләрен «һәм массакүләм мәгълүмат чараларының соравы буенча аларда бастырып чыгару өчен тапшырыла» сүзләренә алмаштырырга, «Керемнәр,» сүзеннән соң «чыгымнар,» сүзен өстәргә;

1 пунктчада «керемнәр» сүзеннән соң «, чыгымнар» сүзен өстәргә;

г) 3 пунктта «Керемнәр,» сүзеннән соң «чыгымнар,» сүзен өстәргә, «керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр» сүзләрен «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 пунктта «Керемнәр,» сүзеннән соң «чыгымнар,» сүзен өстәргә;

е) 6 пунктта «керемнәр,» сүзеннән соң «чыгымнар,» сүзен өстәргә;

4) түбәндәге эчтәлекле 3 нче кушымта өстәргә:

«3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының чыгымнары, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында**
**БЕЛЕШМӘ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе рәисе

_______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Мин, _____________________________________________________________,
(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы)

______________________________________________________________________
_____________________________________________________________________,
(эш урыны һәм биләгән вазыйфасы)

_____________________________________________________________________,
__________________________________________________ адресы буенча яшәүче,
(яшәү урыны адресы)

20_____ елның 1 гыйнварыннан 20____ елның 31 декабренә кадәр хисап чоры ахырына (хисап датасына) җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алуга кагылышлы алыш-бирешләр буенча һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында үз чыгымнарым, шулай ук минем

______________________________________________________________________
(хатынымның (иремнең), балигъ булмаган кызымның, балигъ булмаган улымның)
____________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы)

____________________________________________________________________,
(төп эш яисә хезмәт урыны һәм били торган вазыйфасы;
төп эш яисә хезмәт урыны булмаган очракта – шөгыльләренең төре)

чыгымнары турындагы белешмәләрне хәбәр итәм:

1 бүлек. Күчемсез мөлкәт белән алыш-бирешләр турында белешмәләр

| № т/с | Милеккә сатып алынган мөлкәтнең төре һәм исеме[1] | Милек төре[2] | Урнашкан урыны (адресы) | Алыш-биреш суммасы | Алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

[1] Күчемсез мөлкәт объектының төре (җир кишәрлеге, торак йорт, фатир, дача, гараж, башкалар) күрсәтелә.
[2] Милек төре (индивидуаль, гомуми) күрсәтелә; уртак милек өчен милкенә мөлкәт сатып алынган бүтән затлар (фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә атамасы) күрсәтелә; өлешле милек өчен белешмәләр тапшыручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының (гаилә әгъзасының) сатып алынган өлеше күрсәтелә.

2 бүлек. Транспорт чаралары белән алыш-бирешләр турындагы белешмәләр

| № т/с | Милеккә сатып алынган транспорт чарасының төре һәм маркасы[3] | Милек төре[4] | Теркәлгән урыны | Алыш-биреш суммасы | Алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

[3] Транспорт чарасы төре (җиңел автомобиль, йөк автомобиле, авыл хуҗалыгы техникасы, су транспорты, һава транспорты, башкалар) күрсәтелә.
[4] Милек төре (индивидуаль, гомуми) күрсәтелә; уртак милек өчен милкенә мөлкәт сатып алынган бүтән затлар (фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә атамасы) күрсәтелә; өлешле милек өчен белешмәләр тапшыручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының (гаилә әгъзасының) сатып алынган өлеше күрсәтелә.

3 бүлек. Кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар) белән алыш-бирешләр турында белешмәләр:

| № т/с | Оешманың атамасы һәм оешты-ру-хокукый рәвеше[5] | Оешманың урнашкан урыны (адресы) | Устав капита-лы[6] (рубль-ләрдә) | Сатып алын-ган кат-нашу өлеше | Алыш-биреш суммасы | Алыш-биреш башкарыл-ган акча-ларны алу чыганак-лары |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

20___ елның «____» ____________

______________________________________________________________

(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты имзасы)

______________________________________________________________

(белешмәне кабул итеп алган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм имзасы)

---

[5] Оешманың тулы яисә кыскартылган рәсми атамасы һәм аның оештыру-хокукый рәвеше (акционер җәмгыять, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять, ширкәт, җитештерү кооперативы һәм башкалар) күрсәтелә.

[6] Устав капиталы хисап датасына оешманың гамәлгә кую документлары буенча күрсәтелә. Чит ил валютасындагы устав капиталлары өчен устав капиталы хисап датасына Россия Банкы курсы буенча рубльләрдә күрсәтелә.».

**3 статья**

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10), түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«4. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Хисап палатасы аудиторлары җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары, әгәр алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елдагы төп хезмәт (эш) урыны буенча гомуми кеременнән артса, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының алар нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә тапшырырга тиеш.».

**4 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 2 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлештә «үз керемнәре,» сүзләреннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә, «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның (Татарстан Республикасы Президентыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларыннан тыш) чыгымнарын, шулай ук аларның хатыннарының (ирләренең) һәм

балигъ булмаган балаларының чыгымнарын тикшереп торуны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт органы (дәүләт органы бүлекчәсе йә күрсәтелгән органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты) Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.».

**5 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш), № 12 (VI өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; Ватаным Татарстан, 2013, 2 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

2) беренче өлештә «ел саен» сүзләрен төшереп калдырырга, «тәртиптә» сүзеннән соң «, срокларда» сүзен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ өлешләр өстәргә:

«$1^1$. Муниципаль хезмәтнең тиешле исемлеккә кертелгән вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм рәвеш буенча тапшырырга тиеш.

$1^2$. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, әлеге Законда, Татарстан Респуб-

ликасы Президентының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

4) 2 өлештә «Керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

5) 3 өлештә «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

6) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне фаш итүдә яисә әлеге белешмәләрне Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда файдалануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка ия була.»;

7) 5 өлештә «үз керемнәре,» сүзләреннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә, «керемнәре,» сүзеннән соң «чыгымнары,» сүзен өстәргә;

8) 6 өлештә «, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт» сүзләрен «тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт» сүзләренә алмаштырырга;

9) түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затларның чыгымнарын, шулай ук аларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын тикшереп торуны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт органы (дәүләт органы бүлекчәсе йә күрсәтелгән органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты) Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.».

**6 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $10^1$, $10^3$ һәм $10^4$ статьялары нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) шушы Закон үз көченә кергән көннән соң билгеләнгән сайлауларда сайланган чакырылышлардагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына (Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими профессиональ нигездә эшләүче депутатлардан тыш) карата кулланыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 29 марты
№ 24-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 368. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 6419-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).

3. Муниципаль хезмәт турында 1448-4 номерлы Татарстан Республикасы кодексы проекты хакында (II укылыш).

4. «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 460-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

5. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы

Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында" 459-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

6. «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1447-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 473-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 444-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 7.3 һәм 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 467-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

### 453. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 227474-6 номерлы федераль закон проекты турында (депутат эшчәнлегенә караган чикләүләрне үзгәртү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 227474-6 номерлы федераль закон проектын (депутат эшчәнлегенә караган чикләүләрне үзгәртү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 28 марты
№ 2850-IV ДС

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 454. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышын 2013 елның 28 мартында 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 21 марты
№ 2760-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 455. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 6419-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).

3. Муниципаль хезмәт турында 1448-4 номерлы Татарстан Республикасы кодексы проекты хакында (II укылыш).

4. «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 460-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

5. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында» 459-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

6. «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1447-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 473-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 444-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 7.3 һәм 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 467-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасы Казан шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 468-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 469-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муници-

паль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 475-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 476-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 474-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитетының 2009 елның мартыннан 2013 елның февраленә кадәрге чордагы эшчәнлеге турында хисап.

17. «Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау турында» Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.

18. «Өлкән яшьтәге кешеләрнең проблемалары турында» 1992 елның 1 июнендәге 2890/1-1 номерлы Россия Федерациясе Югары Советы Президиумы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 199673-6 номерлы федераль закон проекты турында.

19. «Россия Федерациясе Торак кодексының 112 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Тыва Республикасы Югары Хуралының (парламентының) закон чыгару инициативасы хакында.

20. «Кавказ арты, Балтыйк буе һәм Таҗикстан Республикасы дәүләтләре территорияләрендә хәрби хезмәт узучы, шулай ук гадәттән тыш хәл һәм хәрби конфликтлар шартларында бурычлар үтәүче хәрби хезмәткәрләргә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр турында» Россия Федерациясе Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Дума-

сына кертү буенча Ненец автономияле округы депутатлары Җыелышының закон чыгару инициативасы турында.

21. «Росатом» Атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе турында” Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мурманск өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

22. Россия Федерациясе Хөкүмәтенә Әстерхан өлкәсе Думасы мөрәҗәгате турында (инвалидларны шифаханә-курорт дәвалануына юлламалар белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча).

23. «Россия Федерациясендә дәүләт яшьләр сәясәте турында» федераль законны кабул итү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары О.Ю. Голодецка Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате хакында.

24. «Россия Федерациясендә туберкулез таралуны кисәтү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате хакында.

25. Ял итү урынына бару һәм багаж алып бару һәм кире кайту бәясен түләү чыгымнарын компенсацияләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында.

26. Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында.

27. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 229781-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

28. «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлау турында» 232119-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

29. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 36 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында.

30. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында.

31. «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның $12^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасы турында.

32. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 225220-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрынраслау өлешендә).

33. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына уен зоналарыннан читтә комарлы уеннарны законсыз оештыруга һәм уздыруга каршы тору мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 188815-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

34. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 217677-6 номерлы федераль закон проекты турында (элек Россия Федерациясеннән административ куып чыгарылган йә депортацияләнгән чит ил гражданының яисә гражданлыгы булмаган затның Россия Федерациясендә яшәүгә хокук алу турында гариза белән мөрәҗәгать итү хокукы чорын Россия Федерациясеннән административ куып чыгарылганнан йә депортацияләнгәннән соң 8 ел итеп билгеләү турында).

35. «Административ хокук бозулар турында 2001 елның 30 декабрендәге 195-ФЗ номерлы Россия Федерациясе кодексының 5.17 статьясының беренче өлешенә өстәмәләр кертү хакында» 209719-6 номерлы федераль закон проекты турында (тиешле җаваплылык субъектын билгеләү турындагы мәсьәлә буенча).

36. «Миграция турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен җинаять җаваплылыгын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 182283-6 номерлы федераль закон проекты турында.

37. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне законсыз пропаганда-

лаган һәм рекламалаган өчен җаваплылыкны көчәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 108866-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

38. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының 171 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Сахалин өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында.

39. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында.

40. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында.

41. Коррупциягә каршы Берләшкән Милләтләр Оешмасының 2003 елның 31 октябрендәге конвенциясенең 20 статьясын ратификацияләү турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Калуга өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгате хакында.

42. «Хәрби хезмәткәрләрнең акчалата кереме һәм аларга аерым түләүләр бирү турында» 2011 елның 7 ноябрендәге 306-ФЗ номерлы Федераль законга бер мәртәбә пособие һәм айлык акчалата компенсация алу хокукына ия һәлак булган хәрби хезмәткәрнең гаилә әгъзалары исемлеген киңәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Приморье крае Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате хакында.

43. «Гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре турында Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 180219-6 номерлы федераль закон проекты турында (бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгын алып бару институтының норматив хокукый җайга салынуын камилләштерү өлешендә).

44. «Россия Федерациясе Җир кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 215937-6 номерлы федераль закон проекты хакында (җир кишәрлекләрен түләүсез алу, шул исәптән индивидуаль торак төзелеше өчен дә, хокукына ия гражданнарның исемлеген инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр белән тулыландыру өлешендә).

45. «Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 225121-6 номерлы федераль закон проекты турында (фермер хуҗалыклары башлыклары тарафыннан аларга җир кишәрлекләре бирелгәндә фермер хуҗалыгының теркәлүен раслый торган документ бирү өлешендә).

46. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 21 марты
№ 2761-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 456. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең попечительлек һәм күзәтү советлары эшчәнлегендә һәм аларга ярдәм күрсәтүдә катнашуы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2009 елның 15 апрелендәге 54-IV ДС номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең попечительлек һәм күзәтү советлары эшчәнлегендә һәм аларга ярдәм күрсәтүдә катнашуы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2009 елның 15 апрелендәге 54-IV ДС номерлы карарына, кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2009 елның 15 апрелендәге
54-IV ДС номерлы карарына
кушымта:

## Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәт күрсәтү стационар учреждениеләре ИСЕМЛЕГЕ

| №№ п/п | Интернат йорт исеме | Телефон | Директор | Урнашу урыны, адресы | Попечительлек советына тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат йортлар | | | | | |
| 1. | «Азнакай өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-85592) 3-08-33 6-06-92 | Шакирова Наилә Аксан кызы | 423304, Азнакай муниципаль районы, Актүбә шәһәр тибындагы поселогы, Комаров урамы, 1 йорт | Галимов Рәзиф Хиражетдин улы |
| 2. | «Аксубай өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-84344) 2-73-88 | Мингулова Роза Галиәхмәт кызы | 423060, Аксубай муниципаль районы, Аксубай шәһәр тибындагы поселогы, Р.Беляев урамы, 2 йорт | Симаков Андрей Анатольевич |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3. | «Актаныш өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-85552)<br>5-12-46<br>5-12-47 | Гәпсәләмова Рәҗүдә Салихҗан кызы | 423730, Актаныш муниципаль районы, Пучы поселогы | Шәрипов Алмаз Хантимер улы |
| 4. | «Алексеевск өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-84341)<br>4-02-09<br>4-02-33 | Фомин Юрий Петрович | 422914, Алексеевск муниципаль районы, Зур Полянка авылы, Озерная урамы, 50 йорт | Липужина Валентина Николаевна |
| 5. | «Әлки өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-84346)<br>74-2-44 | Кузнецов Владимир Александрович | 422885, Әлки муниципаль районы, Юхмачы авылы, Мәктәп урамы, 13 йорт | Хәйруллин Илшат Нәҗип улы |
| 6. | «Арча өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-84366)<br>3-15-17<br>3-15-18 | Гиләҗиев Мулланур Габделнур улы | 422000, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Левитан урамы, 6 йорт | Мусин Роберт Ренат улы |
| 7. | «Баулы өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» ДБУ | (8-85569)<br>6-45-26<br>6-45-56 | Кәлимуллина Татьяна Валентиновна | 423924, Баулы муниципаль районы, Кырым-Сарай авылы, Совет урамы, 59г йорт | Мөхәммәтшин Фәрит Хәйрулла улы |
| 8. | «Буа өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ | (8-84374)<br>3-15-54<br>3-33-79 | Закиров Миннерәфыйк Расыйх улы | 422430, Буа шәһәре, Ефремов урамы, 141 йорт | Шәйхетдинов Рәшит Рәхип улы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9. | «Югары Ослан өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-84379)<br>2-22-05<br>2-23-83 | Серебрякова Элеонора Яковлевна | 422570, Югары Ослан муниципаль районы, Югары Ослан авылы, Печище тракты, 3 йорт | Галәвев Әсфән Галләм улы |
| 10. | «Җәлил өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-85573)<br>6-36-33<br>6-36-34 | Сәлахова Минзөлфия Минҗәит кызы | 423368, Сарман муниципаль районы, Җәлил поселогы, Ленин урамы, 2 йорт | Газизов Генар Җанбәк улы |
| 11. | «Алабуга өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-85557)<br>7-50-84<br>7-07-58<br>7-50-84 | Матвеев Леонид Петрович | 423630, Алабуга шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 82 йорт | Бударин Виктор Николаевич |
| 12. | «Казан өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» ДБУ | (8-843)<br>240-29-21 | Әхмәтгалиев Әлфис Рауил улы | 420075, Казан шәһәре, Дәрвишләр бистәсе, Прибольничная, урамы, 15 йорт | Маврина Лилия Николаевна |
| 13. | «Кайбыч өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» ДБУ | (8-84370)<br>3-42-72<br>3-42-73 | Мәннанов Салихҗан Ваһап улы | 422321, Кайбыч муниципаль районы, Федоровское авылы, Пролетар урамы, 54 йорт | Гафуров Илшат Рәфкать улы |
| 14. | «Корноухово өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» ДБУ | (8-84361)<br>2-72-74<br>2-71-09 | Сатдинова Рәмзия Абдрахман кызы | 422644, Балык Бистәсе муниципаль районы, Корноухово авылы, Ленин урамы, 1 йорт | Кантюков Рәфкать Габделхәй улы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 15. | «Лениногорск өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ | (8-85595) 6-07-03 6-07-05 | Директор вазыйфаларын башкаручы Халикова Роза Зыя кызы | 423254, Лениногорск шәһәре, Октябрь урамы, 184 йорт | Тәхәүтдинов Шәфәгать Фәхразый улы |
| 16. | «Лесхоз өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-84362) 4-43-36 4-43-34 | Нургалиев Илһам Хашим улы | 422062, Саба муниципаль районы, Лесхоз поселогы, Лагерь урамы, 6 йорт | Глушков Геннадий Николаевич |
| 17. | «Мамадыш өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» ДБУ | (8-85563) 2-52-01 2-52-99 | Шрыкова Гүзәл Илдус кызы | 422145, Мамадыш муниципаль районы Шәдче авылы Яшьләр урамы, 13 йорт | Абдуллин Тәлгать Мидхәт улы |
| 18. | «Минзәлә өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ | (8-85555) 3-47-21 | Хәбибуллина Илсия Илдус кызы | 423702, Минзәлә шәһәре, Изыскателей урамы, 1/27 йорт | Водопьянова Татьяна Павловна |
| 19. | «Мөслим өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ | (8-85556) 2-54-70 2-34-91 | Шакирҗанова Гөлнар Гарифҗан кызы | 423970, Мөслим муниципаль районы, Мөслим авылы, Набережная урамы, 22 йорт | Миңнуллин Роберт Мөгаллим улы |
| 20. | «Чаллы өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-8552) 70-46-89 70-44-85 | Зиннуров Барый Минтаһир улы | 423808, Чаллы шәһәре, Казан проспекты, 10 йорт | Евдокимов Александр Сергеевич |
| 21. | «Яңа Чишмә өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» ДБУ | (8-84348) 2-25-90 2-27-03 | Абрамов Петр Иванович | 423190, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 69 йорт | Харисов Ринат Гата улы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 22. | «Нурлат өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-84345)<br>2-46-38<br>2-46-26 | Савинов Евгений Кузьмич | 423040, Нурлат шәһәре, Нурлат урамы, 1 йорт | Салихов Илгиз Мисбах улы |
| 23. | «Спас өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» ДБУ | (8-84347)<br>3-02-67<br>3-05-19 | Федонин Александр Михайлович | 422840, Болгар шәһәре, хирург Г.А. Шеронов урамы, 6 йорт | Логинов Василий Платонович |
| 24. | «Тәтеш өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» ДБУ | (8-84373)<br>5-66-30<br>5-66-33 | Самаркина Людмила Георгиевна | 422374, Тәтеш муниципаль районы, Олы Шәмәк авылы, Пролетар урамы, 36 йорт | Вәлиев Наил Мансур улы |
| 25. | «Тукай өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» ДБУ | (8-8552)<br>79-70-66 | Әхмәтханова Рәмзилә Зиннәт кызы | 423874, Тукай муниципаль районы, Теләнче Тамак авылы, Больничная урамы, 20 йорт | Захарова Светлана Михайловна |
| 26. | «Федоровский өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» ДБУ | (8-84344)<br>4-20-18 | Маланчева Галина Ивановна | 423030, Аксубай муниципаль районы, Федоровский поселогы | Демидов Алексей Алексеевич |
| 27. | «Чирмешән өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКАУ | (8-84396)<br>2-26-72<br>2-24-53 | Мотыйгулллин Җәүдәт Габелҗәдит улы | 423100, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән авылы, Техника урамы, 3 йорт | Сафиуллин Дамир Харун улы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 28. | «Юлдаш» Чистай өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты» СХКДАУ | (8-84342) 4-85-67 4-86-12 | Попова Татьяна Викторовна | 422980, Чистай шәһәре, Полющенков урамы, 15 йорт | Васильев Валерий Павлович |
| 2. Психоневрология интернатлары | | | | | |
| 1. | «Алабуга психоневрология интернаты» СХКАУ | (8-85557) 7-08-04 7-83-18 | Рахматуллин Рәшит Нуретдин улы | 423630, Алабуга шәһәре, М. Горький урамы, 115 йорт | Сафиуллин Илсур Миңнур улы |
| 2. | «Зеленодольск психоневрология интернаты» СХКАУ | (8-84371) 3-35-08 3-71-39 | Ишелина Лариса Анатольевна | 422520, Зеленодольск шәһәре, Гайдар урамы, 15 йорт | Гусев Александр Петрович |
| 3. | «Казан психоневрология интернаты» СХКАУ | (8-843) 234-15-42 234-62-43 | Вәлитов Морат Равил улы | 420075, Казан шәһәре, Дәрвишләр бистәсе, Прибольничная урамы, 1 йорт | Абдуллин Камил Фәргать улы |
| 4. | «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» СХКАУ | (8-84366) 5-22-43 5-22-42 | Гарипов Рамил Мансурович | 420029, Арча муниципаль районы, Яңа Чүриле авылы, Ленин урамы, 34 йорт | Ратникова Римма Атлас кызы |
| 5. | «Чистай психоневрология интернаты» СХКАУ | (8-84342) 5-06-15 5-45-58 | Приданникова Лилия Нияз кызы | 422980, Чистай муниципаль районы, Психинтернат поселогы | Исаева Анастасия Георгиевна |
| 6. | «Кама Аланы тернәкләндерүнең заманча медик-социаль технологияләре кулланылучы психоневрология интернаты» СХКДАУ | (8-8555) 33-50-00 33-50-33 | Хисмәтов Тимур Илсур улы | 423564, Түбән Кама районы, Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы, 4/06 йорт | Вәлиев Разил Исмәгыйль улы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3. Акылга зәгыйфь балалар өчен интернат йортлар | | | | | |
| 1. | «Югары Отар Акылга зәгыйфь балалар өчен интернат йорты» СХКАУ | (8-84362)<br>4-97-29<br>4-97-59 | Гәрәев Имаметдин Гәрәй улы | 422051, Саба муниципаль районы, Югары Отар, Яңа урам, 1 йорт | Паткина Аида Фәнил кызы |
| 2. | «Дербышки акылга зәгыйфь балалар өчен интернат йорты» СХКАУ | (8-843)<br>239-51-15<br>239-50-19<br>239-50-49 | Зарифҗанов Ринат Мөкатдис улы | 420096, Казан шәһәре, Олы Дәрвишләр авылы, Лесная урамы, 1 йорт | Минһаҗетдинов Илдус Әнвәр улы |

Чыгарылма:
СХКАУ – Социаль хезмәт күрсәтү автоном учреждениесе
СХКДАУ – Социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе
ДБУ – Дәүләт бюджет учреждениесе».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары**
**А.П. Гусев**

Казан шәһәре,
2013 елның 21 марты
№ 2763-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 457. З.В. Хәсәнованы Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләүгә тәкъдим итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасының дәүләт үсеше өлкәсендәге хезмәттә югары казанышлары өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Документлар белән тәэмин итү идарәсенең редакцион-лингвистик экспертиза бүлеге мөдире Зәнфирә Васил кызы Хәсәнованы Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләүгә тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары**
**А.П. Гусев**

Казан шәһәре,
2013 елның 21 марты
№ 2764-IV ДС

# III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ ҺӘМ БОЕРЫКЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 458. Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турында

Балаларын тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Тәтеш муниципаль районының Киртәле авылыннан биш бала анасы | Романова Татьяна Ивановнаны |

Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 01 март
№ ПУ-171

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 459. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарәне булдыруга һәм үстерүгә өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районы Олы Мәми авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре | Сальцинова Анна Владимировнаны |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 01 март
№ ПУ-172

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 460. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарәне үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары | Камалиев Нияз Илгиз улын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 01 март
№ ПУ-173

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 461. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Җирле үзидарә органнарында күпьеллык намуслы эшчәнлеге һәм районның социаль-икътисадый үсешенә өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районы Советы оештыру бүлеге башлыгы | Хәбибуллина Халисә Әнвәр кызын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 01 март
№ ПУ-174

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 462. «Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм илебездә машина төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «мефро уилз Руссиа Завод Заинск» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте көпчәк җитештерү цехының салкын ысул белән штамповкалау җиһазлары автомат һәм ярымавтомат линияләре операторы | Калашникова Татьяна Ивановнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 01 марта
№ ПУ-176

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 463. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе «5 номерлы төзәтү колониясе» федераль казна учреждениесе башлыгы, эчке хезмәт полковнигы | Арбузов Юрий Викторовичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 01 март
№ ПУ-177

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 464. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләү турында

Республиканың нефть һәм газ химиясе тармагын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры | Яруллин Рафинат Самат улын |

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казань, Кремль
01 марта 2013 года
№ УП-178

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 465. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга керткән өлеше, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары, эчке хезмәт полковнигы | Дәүлиев Рафаил Гани улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 01 март
№ ПУ-179

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 466. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Җирле үзидарә органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, районның социаль-икътисадый үсешенә өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Тукай муниципаль районы «Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Камилҗанов Зарифҗан Мәхмүт улын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 01 март
№ ПУ-180

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 467. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшендә зур казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Чирмешән үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең хирургия бүлекчәсе табиб-хирургы | Минеголов Рәмил Рәхим улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 01 март
№ ПУ-181

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 468. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм илебездә очкычлар төзү тармагын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Казан вертолет заводы» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры | Лигай Вадим Александровичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 01 март
№ ПУ-182

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 469. Хокук мәсьәләләре буенча тармакара координация комитеты составына үзгәрешләр кертү турында

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Хокук мәсьәләләре буенча тармакара координация комитетын оештыру турында» 2004 елның 19 июлендәге ПУ-490 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 26 декабрендәге ПУ-517 номерлы, 2007 елның 30 апрелендәге ПУ-218 номерлы, 2007 елның 18 декабрендәге ПУ-688 номерлы, 2008 елның 12 маендагы ПУ-206 номерлы, 2008 елның 26 декабрендәге ПУ-686 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-201 номерлы, 2009 елның 7 декабрендәге ПУ-649 номерлы, 2010 елның 15 февралендәге ПУ-69 номерлы, 2010 елның 16 сентябрендәге ПУ-617 номерлы, 2010 елның 30 декабрендәге ПУ-890 номерлы, 2011 елның 19 апрелендәге ПУ-222 номерлы һәм 2012 елның 29 июнендәге ПУ-519 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Хокук мәсьәләләре буенча тармакара координация комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составыннан И.К. Хәйруллинны чыгарырга;

б) Комитет составына Фомин Анатолий Алексеевичны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен кертергә (килешү буенча);

в) Комитет әгъзасы Р.М. Ильясовның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе – Татарстан Республикасының баш суд приставы».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 02 март
№ ПУ-183

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 470. «Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Республиканың оборона сәнәгатен үстерүгә шәхси өлеш кертүе, актив фәнни-тикшеренү һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен

| | |
|---|---|
| «В.И. Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү берләшмәсе» ачык акционер җәмгыятенең шәрәфле директоры | Мостюков Илдус Шәйхелислам улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 04 март
№ ПУ-184

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 471. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Финанс-икътисад эшчәнлегенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге башлыгы | Бобина Людмила Владимировнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 04 март
№ ПУ-185

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 472. «Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә лаеклы өлеш кертүе, актив фәнни-тикшеренү һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен

| | |
|---|---|
| «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениеcе Тарих институтының гомуми тарих һәм укыту методикасы кафедрасы профессоры | Борһанов Альберт Әхмәтҗан улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 04 март
№ ПУ-186

## 473. Татарстан Республикасының Балтач районы Пүскән авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлегe сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының Балтач районы Пүскән авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Азнакай районының Чалпы авылындагы Яшьләр урамы;

Аксубай районының Иске Киязле авылындагы Яшьләр урамы;

Алабуга шәһәрендәге Урман урамы;

Зәй районының Бигеш авылындагы Гагарин урамы;

Нурлат районының Аксумла авылындагы Елга аръягы урамы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 04 март
№ ПУ-187

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 474. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Республиканың төзелеш тармагы үсешенә зур өлеш кертүе һәм намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татинвестгражданпроект» баш территориаль проектлау-тикшеренү фәнни-җитештерү фирмасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры, Казан шәһәре | Хөснетдинов Адель Альберт улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 04 март
№ ПУ-189

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 475. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшендә казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Чулпан-медицина» дәвалау-профилактика үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең терапия бүлекчәсе мөдире, Түбән Кама шәһәре | Биктимерова Флера Рафаил кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 04 март
№ ПУ-190

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 476. «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының нефть сәнәгатен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Консалтинг Үзәге» ябык акционер җәмгыятенең персонал белән идарә итү бүлеге башлыгы, Әлмәт шәһәре | Бродская Лидия Ивановнаны |

«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 05 март
№ ПУ-191

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 477. «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләү турында

Нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының нефть эшкәртү тармагын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Татнефть-АЗС Үзәк» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорының техник ярдәм күрсәтү буенча урынбасары, Әлмәт шәһәре | Горбунов Сергей Дмитриевичны |

«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 05 март
№ ПУ-192

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 478. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Эшендә югары күрсәткечләргә ирешүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе финанс бүлеге башлыгы | Аскеркова Ирина Юрьевнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 05 март
№ ПУ-195

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 479. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тикшерү хезмәте башлыгы урынбасары | Каменов Сергей Геннадьевичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 05 март
№ ПУ-196

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 480. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Намуслы хезмәтләре, югары һөнәри осталыклары һәм наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәшү өлкәсендәге казанышлары өчен Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешенә контроль буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| оператив хезмәт башлыгы | Казакулов Юрий Олеговичны |
| Чаллы районара бүлеге башлыгы | Князькин Олег Николаевичны |
| оператив хезмәт бүлеге башлыгы | Мясников Максим Владимировичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 05 март
№ ПУ-197

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 481. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Эшендә югары күрсәткечләргә ирешүе һәм намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе поликлиникасы табиб-терапевты | Әмирова Миләүшә Харис кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 05 март
№ ПУ-198

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 482. Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү буенча эшчәнлекне камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү тәртибе турында» 2008 елның 5 сентябрендәге ПУ-445 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-211 номерлы, 2010 елның 18 августындагы ПУ-536 номерлы, 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы һәм 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән

кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 11 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Эш төркеме тарафыннан түбәндәге килешү проектлары карала алмый:

Россия Федерациясе бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар бирүне күздә тотучы;

Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзалары тарафыннан кул куелучы.»;

б) 12 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар бирүне күздә тотучы килешүләр проекты килешү төзүне тәкъдим итүче Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (Татарстан Республикасы дәүләт органы, оешмасы) тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына килештерүгә җибәрелә.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзалары тарафыннан кул куелучы килешү проекты килешү төзүне тәкъдим итүче Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (Татарстан Республикасы дәүләт органы, оешмасы) тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынган органнарына, башка органнар һәм оешмаларына килештерүгә җибәрелә.»;

в) 13 пунктта «эш төркеме» сүзләрен «эш төркеме тарафыннан яисә, килешү проекты эш төркеме тарафыннан карарга тиеш булмаган очракта, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынган органнары, башка органнар, оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 06 март
№ ПУ-199

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 483. «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Физик культура һәм спортны үстерүдәге казанышлары, намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» муниципаль учреждениесе башлыгы урынбасары | Шәйдуллин Илшат Равил улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 06 март
№ ПУ-200

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 484. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы | Шабаев Фаяз Баян улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 06 март
№ ПУ-201

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 485. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Сон авыл Мәдәният йорты директоры | Хуҗин Фәрит Габделхак улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 06 март
№ ПУ-202

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 486. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшендә зур казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасының табиб-психиатры | Сөләйманова Динара Миңнехан кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 06 март
№ ПУ-203

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 487. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы | Әмиров Заһир Фәхразый улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-204

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 488. «Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Элемтә чараларын үстерүгә өлеш кертүе һәм наркомания таралуга каршы көрәшү өлкәсендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе махсус элемтә бүлеге башлыгы | Сафин Рамил Рәшит улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-205

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 489. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә класслы чиннар бирү турында

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә түбәндәге класслы чиннарны бирергә:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы буенча

**Татарстан Республикасының**
**2 класслы хакыйкый дәүләт киңәшчесе**

| | |
|---|---|
| министрның беренче урынбасары | Вафин Гадел Юныс улына |
| министр урынбасары | Җәләлетдинов Ринат Сәгыйть улына |
| министр урынбасары | Яркәева Фәридә Фатыйх кызына |

**Татарстан Республикасының**
**3 класслы хакыйкый дәүләт киңәшчесе**

| | |
|---|---|
| министр урынбасары | Осипов Сергей Альбертовичка |
| министр урынбасары | Шишмарева Елена Ивановнага |

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы буенча

**Татарстан Республикасының**
**3 класслы хакыйкый дәүләт киңәшчесе**

| | |
|---|---|
| министр урынбасары | Шәмиев Рөстәм Илдар улына |

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-206

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 490. Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты турында Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасында Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты оешу белән бәйле рәвештә, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты турындагы Нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-207

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның 07 мартындагы
ПУ-207 номерлы
Указы белән расланды

### Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты турында Нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты (алга таба – Департамент) Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының структур бүлекчәсе булып тора, Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә турыдан туры буйсына.

2. Департамент Татарстан Республикасының эчке сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан үзенең конституциячел вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын тәэмин итү максатларында төзелде.

3. Департамент үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә,

федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында Нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Департамент турында Нигезләмә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тәкъдиме буенча раслана.

## II. Департаментның төп бурычлары

5. Департаментның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә торган эчке сәясәтен этноконфессиональ һәм иҗтимагый-сәяси өлкәләрдә гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Президентының сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, иҗтимагый һәм дини берләшмәләр, коммерциячел булмаган башка оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Президентына тиешле докладлар әзерләү максатларында республикадагы социаль-сәяси вазгыять, булуы көтелә торган әһәмиятле вакыйгалар, сайлау кампанияләре барышы, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр, сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, иҗтимагый, дини һәм коммерциячел булмаган башка оешмалар һәм граждан җәмгыятьләре эшчәнлеге, аларның республикадагы эчке сәясәтенең төп мәсьәләләренә мөнәсәбәте, шулай ук әлеге мәсьәләләргә карата массакүләм мәгълүмат чаралары позициясе турында мәгълүмат туплау, аны гомумиләштерү һәм анализлау;

Татарстан Республикасында сәяси процесслар үсешен анализлау һәм фаразлау, алынган мәгълүматларга нигезләнеп, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары, сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, иҗтимагый, дини һәм коммерциячел булмаган башка оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары белән консультацияләр уздыру, Татарстан Республикасы Президенты өчен тиешле мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү;

сәяси планлаштыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр әзерләү.

## III. Департаментның төп функцияләре

6. Департаментның төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

социаль-сәяси вазгыять, дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, конфессияләр эчендә барган һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышы буенча мәгълүмати-аналитик материалларны әзерләү, гомумиләштерү һәм системалаштыру;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, дәүләт хакимиятенең башка органнары эшчәнлеге, шулай ук сайлау кампанияләре барышы турында һәм эчке сәясәтнең башка мәсьәләләре буенча җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү;

Татарстан Республикасы Президентына иҗтимагый үсешнең актуаль мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү;

Татарстан Республикасы Президентына Департамент карамагындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Президентының, шулай ук башка вазыйфаи затларның Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары, коммерциячел булмаган оешмалар һәм граждан җәмгыятенең башка институтлары уздыра торган чараларда катнашуына бәйле тәкъдимнәр бирү;

Татарстан Республикасы Президентының сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, иҗтимагый, дини һәм коммерциячел булмаган башка оешмалар лидерлары, фән һәм иҗат интеллигенциясе, халыкның төп социаль төркемнәре вәкилләре белән очрашуларын әзерләүдә катнашу;

үз компетенцияләре чикләрендә, вәкаләтле органнар белән бергәләп, Татарстан Республикасының мәгълүмат өлкәсендәге сәясәтен формалаштыру һәм гамәлгә ашыруда катнашу, Департамент эшчәнлеге мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек;

Татарстан Республикасында иҗтимагый-сәяси, этник һәм дини вазгыятькә кагылышлы социологик тикшеренүләр һәм мониторинг оештыру;

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юлламалары өчен материаллар әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Президентының Департамент карамагындагы мәсьәләләр буенча мәкаләләре, мөрәҗәгатьләре һәм чыгышлары тезисларын әзерләү;

Татарстан Республикасы Президентының Департамент карамагындагы мәсьәләләр буенча указлары, боерыклары һәм йөкләмәләре проектларын әзерләүдә катнашу;

Департамент карамагындагы мәсьәләләр буенча закон актларын кабул иткәндә һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән үзара хезмәттәшлек;

үз компетенцияләре чикләрендә Татарстан Республикасы Президенты указлары, боерыклары һәм йөкләмәләре, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе боерыклары һәм йөкләмәләре үтәлешен тикшерүләрне оештыруда, аларны контрольдән алуның, башка чаралар күрүнең максатка ярашлыгы турында бәяләмәләр әзерләү;

иҗтимагый-сәяси үсеш, дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, конфессияләрдәге мөнәсәбәтләргә кагылышлы мәсьәләләр буенча фәнни-гамәли конференцияләр, семинарлар, түгәрәк өстәлләр эшендә катнашу;

дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының дәүләтнең милли сәясәтен гамәлгә ашыру һәм конфессияләрдәге мөнәсәбәтләр, иҗтимагый-сәяси үсеш һәм граждан җәмгыяте институтларының функцияләве мәсьәләләренә күзәтчелек итүче хезмәткәрләрен әзерләүдә һәм аларның квалификациясен күтәрүне оештыруда катнашу;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләренең Департамент карамагындагы мәсьәләләр буенча эш тәҗрибәсен гомумиләштерү, аларның эшчәнлеген методик яктан тәэмин итү;

гомумроссия һәм төбәк иҗтимагый һәм дини берләшмәләр, сәяси партияләр һәм аларның бүлекчәләре белән Департамент карамагындагы мәсьәләләр буенча багланышларны һәм элемтәләрне үстерү;

Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе йөкләмәләре буенча башка функцияләрне гамәлгә ашыру.

## IV. Департаментның хокуклары

7. Үз функцияләрен тормышка ашыру өчен Департамент түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт Со-

веты Аппаратыннан, Татарстан Республикасы министрлыкларыннан һәм ведомстволарыннан, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан кирәк булган материалларны билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм алырга;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының, Татарстан Республикасы министрлыкларының, ведомстволарының, шулай ук аларның структур бүлекчәләренең мәгълүмати белешмәләр банкыннан билгеләнгән тәртиптә файдаланырга;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары мәгълүмати-аналитик, тикшеренүләр уздыру хезмәтләре һәм бүлекчәләренең эчке сәясәтнең өстенлекле мәсьәләләре буенча (килештерелгән проектларны гамәлгә ашыру өчен турыдан-туры гомуми планлаштыру һәм ресурсларны берләштерү өлешендә) планнарын һәм оператив эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашырырга;

Департамент эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тикшеренүләр, конференцияләр, семинарлар, конкурслар, башка ачык акцияләр һәм чаралар оештырырга;

белгечләрдән, галимнәрдән эксперт советлары һәм иҗади төркемнәр оештырырга, шулай ук, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе белән килештереп, тиешле үзәкләрне һәм учреждениеләрне шартнамәләр нигезендә җәлеп итәргә;

тематик мәгълүмати-белешмәлек һәм аналитик материаллар, дайджестлар, шул исәптән электрон формада, чыгарырга;

милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне җайлауга, Татарстан Республикасының иҗтимагый-сәяси үсешенә зур өлеш керткән гражданнарны бүләкләү һәм аларны дәүләт бүләкләренә күрсәтү турындагы тәкъдимнәр кертергә;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының тиешле бүлекчәләре гамәлгә ашыра торган финанс, матди-техник һәм башка тәэминаттан билгеләнгән тәртиптә файдаланырга;

Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе каравына Департамент карамагындагы мәсьәләләр буенча эшне камилләштерүгә кагылышлы тәкъдимнәр кертергә.

## V. Департаментның хезмәттәшлелеге

8. Департамент үз функцияләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, Татарстан Респуб-ликасында җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте федераль органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары, шул исәптән түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчеләре белән – Татарстан Республикасы Президентына аның йөкләмәләрен үтәү турында вакытында, тулы һәм объектив мәгълүмат бирү һәм Департамент белән бергәләп чараларны уздырганда тиешле докладлар һәм белешмә материаллар бирү мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты белән – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең милли һәм конфессиональ мөнәсәбәтләр, граждан җәмгыяте институтлары белән багланышлар өлкәсенә караган мәсьәләләргә кагылышлы эшчәнлеген тәэмин итү буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе белән – Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округларында Департамент эшчәнлеге һәм чаралары юнәлешләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе белән – Департамент компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм боерыкларын әзерләгәндә;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе белән – Департамент компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Президенты катнашында чаралар оештырганда;

Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты белән – Татарстан Республикасының сәяси партияләре һәм хәрәкәтләре, иҗтимагый һәм дини берләшмәләре вәкилләре катнашында тышкы элемтәләрне гамәлгә ашыру һәм халыкара элемтәләрне үстерү мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты белән – дәүләт граждан хезмәте, кадрлар сайлау, Департамент хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм стажировкалары мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе белән – сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, иҗтимагый, дини һәм коммерциячел булмаган башка оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары эшчәнлегенә бәйле хатларны һәм гаризаларны караганда;

Татарстан Республикасы Президентының Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе белән – документлар әйләнеше, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе йөкләмәләрен үтәүгә контроль һәм архив фондын комплектлау мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсе белән – Департамент хезмәткәрләре өчен тиешле хезмәт шартлары булдыру һәм аларның социаль көнкүреше мәсьәләләрен хәл итү мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Эксперт идарәсе белән – Татарстан Республикасы Президентына Департамент компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүматианалитик материаллар әзерләү мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге белән – сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, иҗтимагый, дини һәм коммерциячел булмаган башка оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары вәкилләрен бүләкләү мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте белән – Департамент тарафыннан әзерләнгән, Татарстан Республикасы Президенты кул куйган материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару мәсьәләләре буенча.

## VI. Җаваплылык

9. Департамент хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе раслаган вазыйфаи регламентлар нигезендә аларга йөкләнгән бурычларны үз вакытында һәм сыйфатлы итеп үтәү өчен җаваплы булалар.

## VII. Департамент эшчәнлеген оештыру

10. Департаментның структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

11. Департаментның структур бүлекчәләре түбәндәгеләр:

дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләр бүлеген һәм мәгариф программалары һәм проектлары бүлеген үз эченә алган Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе;

Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе;

иҗтимагый-сәяси һәм коммерциячел булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек бүлеген һәм гамәли тикшеренүләр һәм проектлар бүлеген үз эченә алган Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе.

12. Департамент эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе (алга таба – Департамент җитәкчесе) җитәкчелек итә, ул үз вазыйфасына Татарстан Республикасы Президенты указы белән Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тәкъдиме буенча билгеләп куела һәм аннан азат ителә.

13. Департамент җитәкчесе:

Департамент эшчәнлеген оештыра;

Департаментның һәм аның идарәләренең эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгели;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе каравына Департамент структурасы, штат расписаниесе, Департамент хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп кую, күчерү һәм эштән азат итү, аларны бүләкләү һәм аларга дисциплинар җәза бирү турында тәкъдимнәр кертә;

Департамент идарәләре башлыклары, бүлек мөдирләре һәм башка хезмәткәрләр арасында биремнәр һәм йөкләмәләр бүлә;

Департаментның төп эшчәнлеген планлаштыруны оештыра;

Департаментның төп функцияләрен гамәлгә ашыруны җайга салучы эчке документларны раслый;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе каравына Департамент карамагындагы мәсьәләләр буенча оешмалар һәм белгечләр белән шартнамәләр төзү турында тәкъдимнәр кертә;

Департаментка йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

14. Департамент җитәкчесе вакытлыча эш урынында булмаган чорда аның вазыйфаларын урынбасары яисә Департаментның башка вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

15. Департамент җитәкчесе урынбасарлары һәм Департамент идарәләре башлыклары вазыйфага Татарстан Республикасы Президенты боерыгы нигезендә билгеләп куела һәм азат ителә. Департаментның башка хезмәткәрләре вазыйфага Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан Департамент җитәкчесе тәкъдиме буенча билгеләп куела һәм азат ителә.

16. Департамент хезмәткәрләре эшчәнлеге Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар белән җайга салына.

17. Департаментның хезмәт язышып торуын алып бару өчен аның билгеләнгән үрнәктәге, бүлекчәнең тулы атамасы күрсәтелгән бланкы була.

18. Департамент эшчәнлеген мәгълүмати, документлар белән, матди-техник, транспорт белән тәэмин итүне, шулай ук хезмәткәрләргә социаль-көнкүреш, медицина хезмәте күрсәтүне Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының тиешле структур бүлекчәләре башкара.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 491. Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында

Аерым затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфа атамаларының үзгәрүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия турында» 2002 елның 31 гыйнварындагы ПУ-66 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 19 июлендәге ПУ-479 номерлы, 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-5 номерлы, 2010 елның 21 июлендәге ПУ-474 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-586 номерлы, 2011 елның 2 апрелендәге ПУ-181 номерлы һәм 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-626 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия составына (алга таба –

Комиссия), Комиссия әгъзаларының вазыйфаларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

З.Р. Вәлиеваның – «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы директоры, «Татарстан хатын-кызлары» республика иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)»;

Л.Н. Шәфигуллинның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Таттелеком» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» 2004 елның 31 декабрендәге ПУ-824 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 7 декабрендәге ПУ-479 номерлы, 2009 елның 29 гыйнварындагы ПУ-35 номерлы һәм 2011 елның 7 сентябрендәге ПУ-549 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан З.Р. Вәлиеваны, И.М. Ибраһимовны, З.Д. Сөнгатуллинаны, А.И. Шутиковны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Корбанов Рафис Харис улын – Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисен (килешү буенча);

Таишев Марсель Мазһар улын – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисен (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзасы А.М. Терентьевның вазыйфа атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе»;

г) Комиссия әгъзасы А.М. Сибагатуллинны Комиссия рәисе урынбасары итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында өстенлекле милли проектларны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2006 елның 23 гыйнварындагы ПУ-19 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 4 июлендәге ПУ-340 номерлы, 2008 елның 31 гыйнварындагы ПУ-39 номерлы һәм 2011 елның 15 июнендәге ПУ-350 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән),

3 пунктта «Гыйльметдинов Альберт Харис улын» сүзләрен «Фәттахов Энгель Нәвап улын» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсен оештыру һәм координацияләү чаралары турында» 2007 елның 8 сентябрендәге ПУ-511 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-204 номерлы, 2009 елның 5 сентябрендәге ПУ-482 номерлы, 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-235 номерлы һәм 2012 елның 11 июнендәге ПУ-457 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан В.Г. Карузинны, М.Я. Моратовны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Кадыйров Рөстәм Раиф улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгын;

Миңнәхмәтов Ирек Җәүдәт улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында административ реформаны гамәлгә ашыру комиссиясе турында» 2006 елның 14 июнендәге ПУ-220«А» номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 25 апрелендәге ПУ-230 номерлы, 2010 елның 28 июнендәге ПУ-408 номерлы һәм 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-714 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында административ реформаны гамәлгә ашыру комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Н.А. Никифоровны, Ә.Ә. Сәфәровны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Шәйхетдинов Роман Александровичны – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрын;

Хохорин Артём Валерьевичны – Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрын (килешү буенча).

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү эшен оештыру һәм ихтыяҗны билгеләүне координацияләү чаралары турында» 2008 елның 30 апрелендәге ПУ-190 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 10 июлендәге ПУ-319 номерлы, 2008 елның 5 сентябрендәге ПУ-444 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-203 номерлы, 2009 елның 14 октябрендәге ПУ-524 номерлы, 2010 елның 3 июлендәге ПУ-428 номерлы, 2010 елның 12 августындагы ПУ-527 номерлы, 2010 елның 13 декабрендәге ПУ-805 номерлы, 2011 елның 19 апрелендәге ПУ-223 номерлы һәм 2012 елның 3 мартындагы ПУ-171 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.Х. Газизовны, А.Х. Гыйльметдиновны, Ә.Ә. Сәфәровны, Т.М. Йосыповны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Гәрәев Эдуард Илдус улын – Россия Федерациясе наркотиклар әйләнешенә контрольлек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасарын (килешү буенча);

Фәттахов Энгель Нәвап улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

Хохорин Артём Валерьевичны – Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрын (килешү буенча).

7. Татарстан Республикасы Президентының «Бөтендөнья финанс кризисы шартларында Татарстан Республикасы икътисады үсешен тәэмин итү республика комиссиясе турында» 2008 елның 29 декабрендәге ПУ-696 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 14 апрелендәге ПУ-186 номерлы, 2009 елның 22 июнендәге ПУ-344 номерлы, 2010 елның 15 июнендәге ПУ-382 номерлы, 2010 елның 20 августындагы ПУ-547 номерлы һәм 2012 елның 14 августындагы ПУ-652 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Бөтендөнья финанс кризисы шартларында Татарстан Республикасы икътисады үсешен тәэмин итү республика комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан М.Я. Моратовны чыгарырга;

б) Комиссия составына Миңнәхмәтов Ирек Җәүдәт улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен кертергә.

8. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү мәсьәләләре комиссиясе турында» 2010 елның 11 октябрендәге ПУ-680 номерлы Указы белән (2011 елның 14 февралендәге ПУ-58 номерлы һәм 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү мәсьәләләре комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.Х. Гыйльметдиновны чыгарырга;

б) Комиссия составына Фәттахов Энгель Нәвап улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын кертергә.

9. Татарстан Республикасы Президентының «Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча республика ведомствоара комиссиясе мәсьәләләре» 2010 елның 30 декабрендәге ПУ-891 номерлы Указы белән (2011 елның 24 июнендәге ПУ-378 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Л.Б. Макарованы, Р.А. Немаевны, Х.Г. Шәриповны, Д.В. Шогинны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Габдрахманова Гөлнара Альберт кызын – Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Волков Данил Вертолиевичны – Татарстан Республикасы финанс министры урынбасарын;

Идрисов Рөстәм Фидаи улын – Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспекторны (килешү буенча);

Миңнекәев Алмаз Габдуллаҗан улын – Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча).

10. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-208

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 492. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарәне үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Сахарова Людмила Ивановнаны |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-209

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 493. «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан медицина техникасы һәм фармациясе» дәүләт унитар предприятиесенең 89 номерлы Үзәк район даруханәсе мөдире урынбасары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы | Нуриева Гөлсинә Зариф кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-210

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 494. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман гимназиясе» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы | Салихова Алсу Нисбәт кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-211

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 495. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «54 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең биология укытучысы, Чаллы шәһәре | Хәлимова Рушания Хөббәт кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-212

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 496. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «1 нче номерлы Балалар стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе балалар табиб-стоматологы, Чаллы шәһәре | Шәфикова Фәйзүнә Җәмил кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-214

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 497. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, актив иҗади һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен

| | |
|---|---|
| «КАМАЗ» ачык акционер җәмгыяте автомобиль заводының социаль үсеш һәм көнкүреш бүлеге әйдәүче методисты, Чаллы шәһәре | Сабирҗанов Ринат Рәүф улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-215

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 498. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Кама Тамагы үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы | Минвәлиев Ильяс Илдус улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 07 март
№ ПУ-216

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 499. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлегә сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Азнакай районының Урсай авылы;

Буа районының Янтуган авылы;

Мөслим районының Яңа Усы авылы;

Чирмешән районының Сосновка авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Азнакай шәһәренең Тау асты урамы;

Азнакай районының Мәсгут авылындагы Дуслык урамы;

Азнакай районының Митрәй авылындагы Тау асты урамы;

Аксубай районының Аксубай шәһәр тибындагы поселогындагы Муса Җәлил урамы;

Аксубай районының Иске Узи авылындагы Яшьләр урамы;

Әтнә районының Ташчишмә авылындагы Шамил Усманов урамы;

Баулы районының Яңа Зареченский поселогындагы Вахитов урамы;

Кукмара районының Зур Кукмара авылындагы Елга аръягы урамы;

Лаеш районының Лаеш шәһәрендәге Есенин урамы;

Балтач районы Пыжмара авылының Тукай урамындагы 13-33 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;

Түбән Кама шәһәренең Вахитов урамындагы 9 номерлы йорт яны территориясе;

Спас районы Иске Рәҗәп авылындагы «Хәмидуллин Д.М.» крестьян (фермер) хуҗалыгы;

Лениногорск районының Куакбаш авылы янындагы «Маркс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина-транспорт паркы.

2. Үз көчләрен югалтуларын танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 28 декабрендәге ПУ-1123 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Чирмешән районы Сосновка авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының ае-

рым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 29 декабрендәге ПУ-1140 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 11 март
№ ПУ-218

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 500. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Буа район Советының авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгы | Вәлиева Резеда Нәгыйм кызын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 март
№ ПУ-219

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 501. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Азнакай районының Илбәк авылы;

Тәтеш районының Үтәмеш авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Алексеевск районының Войкино авылындагы Вертинская урамы;

Түбән Кама районының Югары Чаллы авылындагы Тукай урамы;

Теләче районының Олы Мирәтәк авылындагы Яшьләр урамы;

Чирмешән районының Ульяновка авылындагы Үзәк урам;

Азнакай районы Әсәй авыл җирлегенең Митрәй авылыннан көньяк-көнчыгыш юнәлештә 2500 метр ераклыкта урнашкан 10 гектар мәйдандагы җирләре;

Балтач районы Чепья авыл җирлегенең Сырия авылыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә 1500 метр ераклыкта урнашкан 1 гектар мәйдандагы җирләре;

Түбән Кама районының Свердловец авылы янындагы «Химокам-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең бозаулар асрау өчен файдаланыла торган терлекчелек фермасы территориясенең бер өлеше;

Саба районының Мичәнбаш авылы янындагы «Курсабаш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте файдалана торган территориянең бер өлеше;

Чистай районындагы «Тиен» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Багана аучылык хуҗалыгы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудырган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 март
№ ПУ-220

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 502. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге зур казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Буа үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы | Сәмирханов Рөстәм Әбрар улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 март
№ ПУ-221

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 503. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль автоном мәгариф учреждениесе юридик факультетының экологик, хезмәткә хокук һәм граждан процессы кафедрасы мөдире | Сафин Завдат Файзрахман улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 март
№ ПУ-222

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 504. «Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Республиканың транспорт комплексын үстерүгә һәм камилләштерүгә өлеш кертүе, намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Тимер юлларны комплекслы реконструкцияләү һәм тимер юл транспорты объектларын төзү дирекциясе башлыгының беренче урынбасары | Лупанов Анатолий Васильевичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 март
№ ПУ-223

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 505. «Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Агросәнәгать комплексына югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет учреждениесенең терлекчелек технологиясе кафедрасы доценты | Сушенцова Марина Анатольевнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 март
№ ПУ-224

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 506. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Финанс-икътисад эшчәнлегенә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен:

| | |
|---|---|
| «Татех» ябык акционер җәмгыяте генераль директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары – баш бухгалтеры, Әлмәт шәһәре | Сидорова Елена Юрьевнага |
| «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе исәп һәм хисап бүлеге башлыгы | Хәбибрахманова Ризидә Фәрит кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 март
№ ПУ-225

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 507. «Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Республика кинематографиясен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Татарстан Республикасының Кинематографиячеләр берлеге» җәмәгать оешмасы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| кинорежиссёр | Габдрахманов Әнвәр Тәлха улына |
| кинооператор | Галиев Фәрит Үзбәк улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 март
№ ПУ-226

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 508. «Татарстан Республикасының Атказанган терлекчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Терлекчелек өлкәсендә югары күрсәткечләргә ирешүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

Никита Евдокимович Токарликов исемендәге ачык акционер җәмгыяте сөтчелек фермасының машина белән саву операторы, Татарстан Республикасының Әлмәт районы

Шилова Любовь Фёдоровнага

«Татарстан Республикасының Атказанган терлекчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 март
№ ПУ-227

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 509. Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционер җәмгыятьләр исемлегенә үзгәреш кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционер җәмгыятьләр исемлеген раслау турында» 2004 елның 8 октябрендәге ПУ-614 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 20 июнендәге ПУ-264 номерлы, 2005 елның 10 августындагы ПУ-319 номерлы, 2005 елның 8 сентябрендәге ПУ-362 номерлы, 2007 елның 22 гыйнварындагы ПУ-17 номерлы, 2007 елның 23 августындагы ПУ-453 номерлы, 2007 елның 29 декабрендәге ПУ-717 номерлы, 2008 елның 17 гыйнварындагы ПУ-10 номерлы, 2008 елның 20 октябрендәге ПУ-529 номерлы, 2009 елның 24 октябрендәге ПУ-558 номерлы, 2010 елның 12 февралендәге ПУ-65 номерлы һәм 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-22 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татар-

стан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционер җәмгыятьләр исемлегенә, 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 19 пунктны өстәп, үзгәреш кертергә:

«19. «Иннополис Сити» ААҖ.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 14 март
№ ПУ-228

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 510. «Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирү турында

Музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «София Гобәйдуллинаның Заманча музыка үзәге» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең «Яңа музыка ансамбле» сәнгать җитәкчесе, дирижёры | Волченко Анна Семёновнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 14 март
№ ПУ-229

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 511. «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Чаллы шәһәре территориаль бүлеге өлкән белгече | Баянова Фирая Мирзагали кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 14 март
№ ПУ-230

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 512. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Республиканың ягулык-энергетика комплексын үстерүгә өлеш кертүе һәм намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Челтәр компаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары – Икътисадый саклану һәм режим идарәсе башлыгы, Казан шәһәре | Кашапов Алмаз Вахит улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 14 март
№ ПУ-231

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**513. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә районы Бакташ авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлегe сәбәпле карантин кертү турында**

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының Яңа Чишмә районы Бакташ авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Алексеевск районының Красный Баран авылындагы Чапаев урамы;

Лениногорск районының Иске Иштирәк авылындагы Совет, Мәктәп урамнары;

Лениногорск районының Яңа Шөгер авылындагы Чкалов урамы;

Чистай районының Актау авылындагы Елга аръягы урамы;

Арча районы Үрнәк авыл җирлегенең Казанка авылыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә 3500 метр ераклыкта урнашкан 2 гектар мәйдандагы җирләре;

Нурлат районы Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә 2000 метр ераклыкта урнашкан 3 гектар мәйдандагы җирләре;

Балтач районы Сизнер авылының Фрунзе урамындагы 9-11/1 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;

Балтач районы Шода авылының Сабиров урамындагы 24-32 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 15 март
№ ПУ-232

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 514. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының аерым эш органнарын бетерү турында

Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Бетерергә:

Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Икътисадый һәм социаль өлкәдә куркынычсызлык буенча ведомствоара комиссиясен;

Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Җәмгать куркынычсызлыгы буенча ведомствоара комиссиясен.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының ведомствоара комиссияләре турында» 2000 елның 1 февралендәге ПУ-61

номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-513 номерлы, 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-128 номерлы, 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы һәм 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), 1 пункттагы «- икътисадый һәм социаль өлкәдә куркынычсызлык буенча;» һәм «- җәмәгать иминлеге буенча;» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Иминлек Советы, аның аерым эшче органнары составларын үзгәртү һәм алар эшчәнлегенең кайбер оештыру мәсьәләләре турында» 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-513 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-128 номерлы, 2007 елның 12 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы, 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы, 2009 елның 3 июнендәге ПУ-318 номерлы һәм 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 7 пунктның үз көчен югалтуын танырга;

б) 8 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) 1 пунктта «- оборона мәсьәләләре һәм хәрби хезмәткәрләр эшләре буенча;» сүзләрен төшереп калдырырга;».

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының аерым эш органнары составын үзгәртү турында» 2009 елның 3 июнендәге ПУ-318 номерлы Указының 1 һәм 2 пунктларының үз көчләрен югалтуларын танырга.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 19 март
№ ПУ-233

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 515. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының «Алабуга мәдәният һәм сәнгать училищесы» урта һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең баян классы буенча укытучысы | Мироваев Владимир Алексеевичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 20 март
№ ПУ-234

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 516. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм намуслы хезмәтләре өчен:

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Мәдәни-ял учреждениеләренең үзәкләштерелгән системасы» муниципаль бюджет учреждениесе директоры | Рыжова Ольга Владимировнага |
| Казан шәһәре Совет районының «4 номерлы балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе вокал классы укытучысы | Ягъфәрова Раушания Гыйльмулла кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 20 март
№ ПУ-235

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 517. «Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Республикада ветеринария иминлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Тукай район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе ветеринар табиб-бактериологы, ветеринария лабораториясе мөдире | Шәехов Миннегаббас Миннегали улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 20 март
№ ПУ-236

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 518. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Финанс-икътисад эшчәнлегенә зур өлеш кертүе һәм намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш бухгалтеры | Исмаева Розалия Гаяз кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 20 март
№ ПУ-237

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 519. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Баулы районының Бакалы авылы;

Саба районының Өч Нарат авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Баулы районының Потапов-Томбарлы авылындагы Беренче Май урамы;

Минзәлә районының Минзәлә шәһәрендәге Элеватор урамы;

Яңа Чишмә районының Акбүре авылындагы Совет урамы;

Яңа Чишмә районының Рус Волчья Бистәсе авылындагы Яшьләр урамы;

Әлмәт районы Миңлебай авыл җирлегенең Миңлебай авылыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә 1000 метр ераклыкта урнашкан 2 гектар мәйдандагы җирләре;

Әлмәт районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Яңа Никольский авылыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә 1500 метр ераклыкта урнашкан 1 гектар мәйдандагы җирләре;

Зеленодольск районы Акъегет авыл җирлегенең Акъегет авылыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә 3000 метр ераклыкта урнашкан 4,5 гектар мәйдандагы җирләре;

Теләче районының Түбән Саурыш авылы янындагы «ВАМИН Теләче» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланылучы терлек симертү цехы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудырган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 20 март
№ ПУ-238

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 520. «Россия 2018» Республика оештыру комитетын төзү турында

Территориясендә 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты һәм 2017 елгы Футбол буенча конфедерацияләр кубогы матчларын оештыруда һәм үткәрүдә кулланылучы спорт объектлары урнашкан Татарстан Республикасын, күрсәтелгән спорт ярышлары һәм алар белән бәйле башка чараларны уздыруга әзерләгәндә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнары Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының, оешмаларының һәм җәмәгать берләшмәләренең үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында **карар бирәм**:

1. «Россия 2018» Республика оештыру комитетын төзергә.

2. «Россия 2018» Республика оештыру комитеты турында Нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Казан шәһәрен 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын һәм 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләү буенча Республика комиссиясе турында» 2011 елның 24 февралендәге ПУ-82 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) исемендә, преамбуласында, 1 һәм 2 пунктларында «һәм 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионатын» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 нче кушымтаның исемендә, 1 пунктында, 4 пунктның икенче һәм өченче абзацларында, 5 пунктның бишенче абзацында «һәм 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионатын» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) Казан шәһәрен 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын һәм 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләү буенча Республика комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

исемендә «һәм 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионатын» сүзләрен төшереп калдырырга;

Комиссия составыннан К.Ф. Әмировны, Е.Б. Богачевны, З.Р. Вәлиеваны, Е.В. Вдовинны, А.Х. Гыйльметдиновны, В.А. Гогинны, С.А. Когогинны, Б.Д. Менделевичны, Р.Н. Миңнехановны,

Р.Х. Мөбарәкшинны, М.Я. Моратовны, Н.А. Никифоровны, А.К. Шиһабетдиновны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Антонов Александр Валентиновичны – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Бариев Марат Мансур улын – Дәүләт Думасының Физик культура, спорт һәм яшьләр эшләре комитеты рәисенең беренче урынбасары, Россия Олимпия комитеты генераль секретарен (килешү буенча);

Кондратьев Андрей Станиславовичны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру мәсьәләләре бүлеге башлыгын;

Кудряшов Василий Александровичны – Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгын;

Миңнәхмәтов Ирек Җәүдәт улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

Пузырьков Кирилл Юрьевичны – «КАМАЗ» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасарын (килешү буенча);

Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улын – Татарстан Республикасы мәдәният министрын;

Туктаров Фәрид Хәйдәр улын – «Татарстан Республикасында дәүләт стандартлаштыру, метрология һәм сынау төбәк үзәге» федераль бюджет учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

Фәттахов Энгель Нәвап улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

Хохорин Артем Валерьевичны – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрын (килешү буенча);

Шәйхетдинов Роман Александровичны – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрын;

Комиссия әгъзалары вазыйфаларын яңа редакциядә бәян итәргә:

Гыйльметдинов Илдар Ирек улының – «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча)»;

Сәфәров Әсгать Әхмәт улының – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары».

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 20 март
№ ПУ-239

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның 20 мартындагы
ПУ-239 номерлы Указына
1 нче кушымта

## «Россия 2018» Республика оештыру комитеты турында НИГЕЗЛӘМӘ

### I. Гомуми нигезләмәләр

«Россия 2018» Республика оештыру комитеты (алга таба – Республика оештыру комитеты), территориясендә 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты һәм 2017 елгы Футбол буенча конфедерацияләр кубогы матчларын оештыруда һәм үткәрүдә кулланылачак спорт объектлары урнашкан Татарстан Республикасын, күрсәтелгән спорт ярышлары һәм алар белән бәйле башка чараларны уздыруга нәтиҗәле, сыйфатлы һәм үз вакытында әзерләү максатларында төзелгән коллегиаль орган булып тора.

Республика оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

### II. Республика оештыру комитетының максатлары һәм бурычлары

2.1. Республика оештыру комитеты, территориясендә 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты һәм 2017 елгы Футбол буенча конфедерацияләр кубогы матчларын оештыруда һәм үткәрүдә кулланылачак спорт объектлары урнашкан Татарстан Республикасын, күрсәтелгән спорт ярышлары һәм алар белән бәйле башка чараларны уздыруга нәтиҗәле, сый-

фатлы һәм үз вакытында әзерләү максатларында төзелә һәм эшчәнлеген тормышка ашыра.

2.2. Республика оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) Казан шәһәрен 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты һәм 2017 елгы Футбол буенча конфедерацияләр кубогын уздыруга әзерләү буенча республика чаралар планын (алга таба – республика чаралар планы) формалаштыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

2) Казан шәһәрен 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты һәм 2017 елгы Футбол буенча конфедерацияләр кубогын уздыруга әзерләүгә кагылышлы планнар, программалар һәм аерым чараларны гамәлгә ашыруның барышын анализлау, республика чаралар планын үтәүне һәм аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны контрольдә тотуны тәэмин итү;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнары Татарстан республикасы буенча территориаль органнарының (алга таба – федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары), Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнарының), оешмаларның һәм җәмәгать берләшмәләренең Республика оештыру комитеты кабул иткән карарларны гамәлгә ашыру барышында һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләүдә үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр эшләү;

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм җәмәгать берләшмәләренең республика чаралар планын үтәү белән бәйле бурычларны хәл иткәндә үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

2.3 Республика оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

1) законнар нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм җәмәгать берләшмәләреннән Республика оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

2) законнар нигезендә «Россия 2018» оештыру комитеты» автоном коммерциячел булмаган оешмасыннан 2018 елгы

футбол буенча дөнья чемпионаты һәм 2017 елгы Футбол буенча конфедерацияләр кубогы матчларын оештыру һәм уздыруга бәйле Халыкара футбол федерациясенең (FIFA) техник әсбапларын, кулланмаларын, тәкъдимнәрен һәм башка документларны соратып алырга;

3) Республика оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә вакытлы эш төркемнәре төзергә;

4) үз утырышларына билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм җәмәгать берләшмәләренең, «Россия 2018» оештыру комитеты» автоном коммерциячел булмаган оешмасы җитәкчеләрен һәм үзгә вәкилләрен, башка кызыксынган затларны чакырырга;

5) 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионатын һәм 2017 елгы Футбол буенча конфедерацияләр кубогын әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә.

## III. Республика оештыру комитетының составы

3.1. Республика оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан формалаштырыла һәм раслана.

3.2. Республика оештыру комитеты составына Республика оештыру комитеты рәисе, рәис урынбасарлары, секретаре һәм башка әгъзалары керә, алар Комиссия эшендә җәмәгать башлангычында катнаша.

3.3. Республика оештыру комитетының рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты тора.

3.4. Республика оештыру комитеты рәисе:

1) Республика оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итә, Республика оештыру комитеты утырышларында каралачак мәсьәләләр исемлеген, вакытын һәм карау тәртибен билгели;

2) урынбасарлары һәм Республика оештыру комитеты әгъзалары арасында вәкаләтләрне (бурычларны) бүлә;

3) Республика оештыру комитеты эшчәнлеге планы нигезендә утырышларның көн тәртибен, уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

4) үзе булмаган вакытта Республика оештыру комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы итеп урынбасарларының берсен билгеләп куя;

5) Республика оештыру комитеты утырышлары беркетмәләренә һәм башка документларга кул куя.

3.5. Республика оештыру комитеты секретаре:

1) рәис тарафыннан билгеләп куела һәм Республика оештыру комитеты утырышларында катнаша;

2) 5 көннән дә соңга калмыйча, утырышны уздыруның урыны, көне, вакыты турында Республика оештыру комитеты әгъзаларына хәбәр итә, утырышның көн тәртибен һәм материалларын җибәрә;

3) Республика оештыру комитеты утырышларының беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җавап бирә.

3.6. Республика оештыру комитеты әгъзалары:

1) Республика оештыру комитеты утырышында шәхсән үзе катнаша;

2) Республика оештыру комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрен тикшерүгә куя;

3) Республика оештыру комитеты карый торган мәсьәләләр буенча материаллар белән таныша;

4) Республика оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү һәм үтәлешен тикшереп тору буенча кирәкле чараларны башкара.

## IV. Республика оештыру комитетының утырышлары һәм карарлары

4.1. Республика оештыру комитеты утырышлары кимендә ике айга бер тапкыр уздырыла. Республика оештыру комитеты рәисе тарафыннан утырышлар графигы раслана һәм Республика оештыру комитеты әгъзалары игътибарына җиткерелә.

4.2. Кирәк булганда рәис Республика оештыру комитетының чираттан тыш утырышы көнен билгели. Бу очракта секретарь Республика оештыру комитеты әгъзаларына Республика оештыру комитетының чираттан тыш утырышы көненә кадәр 10 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

4.3. Республика оештыру комитеты утырышларына көн тәртибе мәсьәләләре буенча материаллар секретарьга утырышның билгеләнгән вакытына кадәр 15 эш көненнән дә соңга калмыйча бирелергә тиеш. Карау өчен кергән матери-

аллар нигезендә секретарь Республика оештыру комитеты утырышы көн тәртибе проектын формалаштыра һәм, утырыш көненә кадәр 12 эш көненнән дә соңга калмыйча, раслау өчен Республика оештыру комитеты рәисенә тапшыра.

4.4. Республика оештыру комитеты рәисе утырышның көн тәртибен утырыш көненә кадәр 10 эш көненнән дә соңга калмыйча раслый. Республика оештыру комитеты утырышының көн тәртибе расланганнан соң Республика оештыру комитеты каравына мәсьәләләр кертү рәис карары буенча гына мөмкин. Бу очракта Республика оештыру комитеты рәисе Республика оештыру комитеты секретарена утырыш көн тәртибен тулыландырырга һәм бу хакта Республика оештыру комитеты әгъзаларына хәбәр итәргә күрсәтмә бирә.

4.5. Республика оештыру комитеты утырышын рәис яисә аның кушуы буенча рәис урынбасарларының берсе алып бара.

4.6. Республика оештыру комитеты әгъзалары аның утырышларында шәхсән катнаша. Республика оештыру комитеты әгъзасы утырышта булмаган очракта, каралган мәсьәләләр буенча ул үз фикерен язмача бәян итәргә хокуклы.

4.7. Республика оештыру комитеты утырышы, әгәр анда комитет әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы була. Республика оештыру комитеты карары, әгәр аның өчен утырышта катнашучы әгъзаларның кимендә яртысы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Республика оештыру комитеты утырышында көн тәртибе мәсьәләләрен карау һәм тавыш бирү нәтиҗәләре буенча каралар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә. Республика оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәислек итүче кул куя.

4.8. Республика оештыру комитеты кабул итүче карарлар кызыксынган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм җәмәгать берләшмәләренә, «Россия 2018» оештыру комитеты» автоном коммерциячел булмаган оешмасына, башка кызыксынган затларга агымдагы эшчәнлекне гамәлгә ашырганда куллану өчен җиткерелә.

4.9. Республика оештыру комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары проектлары әзерләнергә мөмкин.

## V. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

5.1. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник, документлар белән, мәгълүмати һәм транспорт белән тәэмин итүне Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының тиешле структур бүлекчәләре тормышка ашыра.

5.2. Республика оештыру комитеты «Россия 2018» оештыру комитеты» автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән хезмәттәшлек итә һәм бу оешмага барлык кирәкле мәгълүматны, шул исәптән Татарстан Республикасының 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионатын һәм 2017 елгы Футбол буенча конфедерацияләр кубогын үткәрүгә әзерлеге турында, Республика оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар хакында, республика чаралар планын гамәлгә ашыру турында мәгълүмат бирә.

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның 20 мартындагы
ПУ-239 номерлы Указына
2 нче кушымта

«Россия 2018» Республика оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, комитет рәисе |
| Халиков Илдар Шәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры, комитет рәисе урынбасары |
| Метшин Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы, комитет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Леонов Владимир Александрович | «Казан шәһәрендә 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасы башкарма дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасының генераль директоры, комитет секретаре (килешү буенча) |
| Абдуллин Тәлгать Мидхәт улы | «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасының башкарма директоры |
| Антонов Александр Валентинович | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Афанасьев Михаил Павлович | «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Бариев Марат Мансур улы | Дәүләт Думасының Физик культура, спорт һәм яшьләр эшләре комитеты рәисенең беренче урынбасары, Россия Олимпия комитеты генераль секретаре (килешү буенча) |
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Геллер Яков Вениаминович | «Татарстан Республикасы Дәүләт заказы, инвестиция эшчәнлеге һәм төбәкара элемтәләр агентлыгы» дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры |
| Гыйльметдинов Илдар Ирек улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча) |
| Гусев Александр Петрович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Футбол федерациясе рәисе (килешү буенча) |
| Зарипов Равил Хаммат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Захаров Сергей Дмитриевич | «Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы (килешү буенча) |
| Зыятдинов Марат Галимҗан улы | «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Кондратьев Андрей Станиславович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру мәсьәләләре бүлеге башлыгы |
| Кудряшов Василий Александрович | Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы |
| Мәүликов Альберт Вәзил улы | Федераль таможня хезмәте Идел буе таможня идарәсенең Татарстан таможнясы башлыгы (килешү буенча) |
| Миңнәхмәтов Ирек Җәүдәт улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Мусин Роберт Ренат улы | «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (ачык акционер җәмгыяте)  Директорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Пузырьков Кирилл Юрьевич | «КАМАЗ» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сәфәров Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| Сафин Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Сидоров Артем Георгиевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министры |
| Сорокин Алексей Леонидович | «Россия 2018» оештыру комитеты» автономияле коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Сорокин Валерий Юрьевич | «Связьинвестнефтехим» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Тәхаутдинов Шәфәгать Фәхразый улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Туктаров Фәрид Хәйдәр улы | «Татарстан Республикасында дәүләт стандартлаштыру, метрология һәм сынау төбәк үзәге» федераль бюджет учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Тыгин Александр Васильевич | «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры |
| Фәрдиев Илшат Шәех улы | «Сетевая компания» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Фәррахов Айрат Зәки улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Фәттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры – Россия Федерациясе граждан оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы |
| Хамаев Азат Кыям улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Хохорин Артем Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Чепуштанов Сергей Валерьевич | Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |
| Шакиров Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы рәисе (килешү буенча) |
| Шәфигуллин Айрат Радин улы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 521. Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларының үз көчләрен югалтуларын тану турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын үткәрүгә дәүләт заказы турында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-599 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын үткәрүгә дәүләт заказы турында Нигезләмәгә, 6 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте мәсьәләләре советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт  мәсьәләләре комиссиясе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы  Президенты Аппаратында аттестацияләү һәм квалификация имтиханы уздыруны оештыру турында» 2011 елның 3 мартындагы ПУ-94 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында аттестацияләү һәм квалификация имтиханы уздыруны оештыру турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 29-31 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Квалификация имтиханын, дәүләт хезмәте вазыйфаларының иң югары төркеменә караган «җитәкчеләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче

граждан хезмәткәрләреннән кала, вакытлы хезмәт контракты төзелгән граждан хезмәткәрләре тапшыра.

30. Квалификация имтиханы уздырыла:

а) үзе биләүче граждан хезмәте вазыйфасы буенча класслы чины булмаган граждан хезмәткәренә иң беренче класслы чин бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә;

б) граждан хезмәткәренә, ул граждан хезмәткәренә бирелә торган класслы чиннан югарырак яисә аңа тигез класслы чин каралган граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен алдагы класслы чинда үтү өчен билгеләнгән вакыт узганнан соң, граждан хезмәткәренә бирелүче граждан хезмәте вазыйфасын биләү буенча чираттагы класслы чинны граждан хезмәткәренә бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә;

в) граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең югарырак вазыйфасына билгеләп куйганнан соң, әгәр бу вазыйфа өчен әлеге граждан хезмәткәре ия булган класслы чиннан югарырак класслы чин каралган булса, граждан хезмәткәренә  класслы чин бирү турындагы мәсьәләне  хәл иткәндә.

31. Граждан хезмәткәре инициативасы белән класслы чин бирү турында мәсьәлә хәл ителгәндә, квалификация имтиханы граждан хезмәткәре тарафыннан класслы чин бирелү турында язмача гариза бирелгән көннән өч айдан да соңга калмыйча уздырыла.»;

б) 32 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең квалификация имтиханы уздыру турындагы карары Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең квалификация имтиханы уздыру турындагы боерыгы белән рәсмиләштерелә. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең квалификация имтиханы уздыру турындагы боерыгыныңпроектын эшләүне Департамент башкара.

3. Үз көчләрен югалтуларын танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи окладлары турында» 2003 елның 20 октябрендәге ПУ-781 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының

дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи окладлары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 8 сентябрендәге ПУ-569 номерлы Указы.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 20 март
№ ПУ-240

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 522. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында

«Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия төзергә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 20 март
№ ПУ-241

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның 20 мартындагы
ПУ-241 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында**
# НИГЕЗЛӘМӘ

1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия (алга таба – Комиссия) «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында төзелгән коллегиаль орган булып тора.

2. Комиссия Татарстан Республикасы Президенты указы белән төзелә һәм бетерелә. Комиссия турында Нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Комиссия түбәндәгеләрне карый:

а) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның: Татарстан Республикасы Премьер-министрының, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең, Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарының, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарының, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы министрының, Премьер-министр урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесенең, Татарстан Республикасы министрының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте башка органы җитәкчесе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзасының, Россия Федерациясендә Татарстан Республикасы вәкиленең, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасында Бала хо-

куклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасарының, Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторының, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисенең, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе урынбасарының, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе секретаренең (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затның) вазыйфаи тәртибенә куелган таләпләрне үтәүгә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне;

б) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затка карата чыгымнарны тикшереп тору буенча алынган нәтиҗәләрне.

5. Комиссия утырышы үткәрү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

а) Комиссия рәисенең түбәндәгеләргә нигезләнеп кабул ителгән карары:

Комиссиягә тапшырылган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты (алга таба – Департамент) Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-233 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чикләүләрне үтәвен тикшерү турында Нигезләмәгә туры китереп уздырган тикшерү материаллары;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның вазыйфаи тәртипкә таләпләрне бозу турындагы Комиссия каравына кергән башка материаллар;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка карата чыгымнарны тикшереп тору турында карар кабул иткән затның чыгымнарны тикшереп тору барышында алынган нәтиҗәләрне карау турында Комиссиягә кергән тәкъдиме;

б) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның объектив сәбәпләр аркасында үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләрне бирүнең мөмкин булмавы турында Департаментка кергән гаризасы;

6. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән гариза Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын

биләүче зат тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты исеменә Департаментка әлеге затлар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләрне бирү өчен билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта тапшырыла. Департаментта гариза карала, аның нәтиҗәләре буенча мотивацияләнгән йомгак ясала. Гариза, бәяләмә һәм башка материаллар гариза кергән көннән алып җиде эш көне дәвамында Комиссия рәисенә тапшырыла.

7. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау күздә тотылган Комиссия утырышын үткәрү вакыты Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

8. Комиссия секретаре Комиссия утырышына чыгарылучы мәсьәләләрне әзерләүне тәэмин итә, шулай ук Комиссия әгъзаларына, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелүче мәсьәләләр, утырыш үткәрүнең көне, вакыты һәм урыны турында утырыш көненә кадәр җиде эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итүне оештыра.

9. Комиссия, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

10. Карар кабул иткәндә Комиссиянең барлык әгъзалары тигез хокукка ия була.

11. Әгәр дә Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының берсенә карата аның вазыйфаи тәртибенә яисә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәве хакындагы мәсьәлә каралса, күрсәтелгән Комиссия әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 16-18 пунктларында каралган карар кабул иткәндә тавыш бирү хокукына ия булмый.

12. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, үзенә карата мәсьәлә каралган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат катнашында үткәрелә. Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләве турында Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат әлеге Нигезләмәнең 5 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә тапшырылучы гаризада күрсәтә. Мондый күрсәтүдән тыш Комиссия утырышы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче заттан башка үткәрелә.

13. Комиссия утырышына Комиссия рәисе карары белән Татарстан Республикасы дәүләт органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары, шулай ук кызыксынган органнар һәм оешмалар вәкилләре чакырылырга мөмкин.

14. Комиссия утырышына, Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның аңлатмасы тыңлана һәм утырыш көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләргә караучы материаллар тикшерелә. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның үтенече буенча, башка затлар да тыңланырга һәм алар тапшырган материаллар каралырга мөмкин.

15. Комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашучы затлар Комиссия эше барышында аларга билгеле булган мәгълүматны башкаларга хәбәр итәргә хокуклы түгел.

16. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктындагы «а» пунктчасының икенче һәм өченче абзацлары нигезендә материалларны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә ала:

а) каралучы очракта Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан вазыйфаи тәртипкә таләпләрне бозу билгеләре булмавын билгеләргә;

б) каралучы очракта Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан вазыйфаи тәртипкә таләпләрне бозу билгеләре булуын билгеләргә.

17. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктындагы «а» пунктчасының дүртенче абзацы нигезендә тәкъдимне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка юридик җаваплылык чарасын куллану (яисә кулланмау) турында тәкъдим булган карар кабул ителә.

18. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацы нигезендә гаризаны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителергә мөмкин:

а) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне бирмәвенең сәбәбен объектив һәм нигезле дип танырга;

б) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне бирмәвенең сәбәбен нигезле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне бирмәвенең сәбәбен объектив түгел һәм күрсәтелгән белешмәләрне бирүдән тайпылу ысулы булып тора, дип танырга.

19. Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре булган гамәлләре (гамәл кылмавы) билгеләнгән очракта, Комиссия секретаре Комиссия рәисе кушуы буенча күрсәтелгән гамәл (гамәл кылмау) турында мәгълүматны һәм мондый фактны раслаучы документларны өч көн эчендә, ә кирәк булганда – кичекмәстән, хокук куллану органнарына җибәрә.

20. Комиссия карарлары утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән коллегиаль кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

21. Комиссия карары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга утырышта катнашучы Комиссия әгъзалары кул куя.

22. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышының вакыты, Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) Комиссия утырышында каралучы һәр мәсьәләнең, аңа карата мәсьәлә карала торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы күрсәтелгән формулировкасы;

в) Комиссия утырышы үткәрү өчен нигез булырлык мәгълүмат чыганагы һәм Департаментка мәгълүматның керү вакыты;

г) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның һәм башка затларның каралучы мәсьәләләрнең асылы буенча аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача бәян ителүе;

е) башка белешмәләр;

ж) тавыш бирү нәтиҗәләре;

з) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

23. Комиссия карары белән риза булмаган Комиссия әгъзасы язмача рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы, ул Комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри төстә теркәп куелырга тиеш.

24. Комиссия утырышы беркетмәсенең өземтәләре Комиссиянең тиешле утырыш булган көннән соң өч көн эчендә аңа карата мәсьәлә каралган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка, шулай ук аны билгеләү (сайлау, раслау) өчен вәкаләтле затка (Татарстан Республикасы дәүләт органына) җибәрелә.

25. Комиссия карарына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

26. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм документлар белән тәэмин итү Департамент һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының тиешле структур бүлекчәләре тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның 20 мартындагы
ПУ-241 номерлы Указына
2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Комиссия рәисе |
| Белов Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты җитәкчесе, Комиссия секретаре |
| Мөхәммәтшин Фәрид Хәйрулла улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе (килешү буенча) |
| Халиков Илдар Шәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры |
| Камалтынов Юрий Зимелевич | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе |
| Бәдретдинов Марс Сарыйм улы | Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Волкова Фәридә Рәхим кызы | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы |

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 523. Татарстан Республикасының Инвестиция советы составына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасының Инвестиция советы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

